

Фирүзә Жамалетдинова



# Тулымлы ай

*Шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Ж 17

**Җамалетдинова Фирүзә**

Ж 17 Толымлы ай: Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 174 б.

Җыентыкка шагыйрәнең тормышка һәм кешеләргә булган ихлас мәхәббәтен, туган җиренә тирән ихтирамын чагылдырган фәлсәфи-лирик шигырьләре тупланган.

ISBN 5-298-01374-0 © Татарстан китап нәшрияты, 2004

## Сигезенче могҗиза

Киләчәккә ышанмыйм, дип,
Уй уйларга оялам.
...Пирамида төзеткәннәр,
Таш кистерел кыядан
Безнең эраларга кадәр.
...Һич кенә түгел ялган:
Шәһәрләр көлгә әйләнгән —
Пирамидалар калган.
Җиде могҗизасы җирнең!
Уйларга батам, тынам.
...Һаман кояш астында без,
Пирамидалар сыман.
Утка тотып караганнар,
Талчыбыктай сындырып,
Чукындырып караганнар,
Илне, йортны яндырып.
Дәүләтсез, динсез иткәннәр,
Телсез дә без диярлек.
Безгә тигән кайнар уктан
Тарих үзе көярлек.
Пирамидалар шикелле,
Мәңгелектер, төздер без.
Сигезенче могҗизасы
Шушы җирнең бездер. Без!

* * *

Ай еракта. Нур-ачкычы белән
Ачмак булып бар дөньяның биген,
Мин сайлаган депутаттай, җиргә
Хәйлә аша карап тора бүген.

Ай биектә. Минем канат җирдә...
Йөзәбез күк әмма бер үк күктә.
Бирелгәне — нибары бер гомер,
Бик аз да бу безгә һәм бик күп тә.

Ай еракта миннән. Кайчагында
Ышанасы килә вәгъдәләргә.
«Бик сагынсаң, айга кара», — диеп
Җырга кергән кичке дәгъваларга.

Кешеләргә ышанасы килә,
Эндәшәсе: Бәхет минә кайда!
Үз-үзеңә ышанасы килә,
Ышанасы килә кайчак айга.

# Тузганак

Әй тузганак! Өрмим! Өрмим!
Өрсәм, тузасың инде.
Безнең дә соң... Гомерләр соң...
Шулай уза соң инде...

Җил үзәгендә уйныйсың,
Җил сине туздырмаган.
Туздыруда адәм заты
Кемнәрне уздырмаган!

Тузганактай башлар очкан —
Өргәннәр, очырганнар.
Бардан юкка чыгуларны
Кызык санап торганнар.

Башлар очкан зиндангача,
Башлар очкан Себергә.
Очырганнар яшәр җир һәм
Ил белән бергә-бергә.

Җилләр белән шаярасың,
Өрсәм, син дә тузасың...
...Тузганакка да теләмим
Мин халкымның нужасын.

# Үз көнем

Көннең төсе нинди микән бүген?
Бәлки, кызыл, бәлки, карадыр?
Ә кичәге — үзе якын, үзе
Күз күреме җитмәс арадыр.

Бае — байдыр, ярлылары — ярлы,
Без төшенмәс меңләп юл торган.
Хәерчесе алларына тишек
Эшләпәсен куеп утырган.

Ә кичә ул, күзләренә төшереп,
Күк эшләпә кия алгандыр.
Шул эшләпә аркасында, бәлки,
Коммунизм күрми калгандыр...

Җәелергә тормый кочагы ла,
Сүнгән мәллә көннең учагы?
Тумаса да монда, җиде бабам
Туфрагы, дип кайткан качагы.

Һәм халыклар кайткан нигезенә,
Үз-үзенә кайта халыклар.
Итекләр дә төрле, читекләр дә,
Төрле булыр, бәлки, калыплар.

Көннең төсе, бәлки, карадыр да,
Килә аны гөлгә төрәсе.
Хәер, акмы, зәңгәрме ул, алмы —
Үз көнемне үзем күрәсе.

* * *

Октябрьдә туганнарның
Ленин була бабасы.

*Жырдан*

Октябрьдә тумаганга,
Елаган идем мин дә.
Кызыл галстуклар гүя
Канатлар иде индә.

Кичә генә иде әле
Озын-озын чиратлар.
Сабыр гына көтә иде
Әзмәвердәй ир-атлар.

Мавзолейлар тирәсе буш,
Тормыш бүтән, замана.
Бүген һәркем, иртәгегә
Акчам юк, дип зарлана.

Бүген бар да тарих яза,
Сүзсез генә сулкылдап.
Ни эшләнсә, шул эшләнә
Кебек бары сул кулдан.

Син дә менә буталгансың,
Исәбе юк айларның.
Тик хыялың охшап тора
Коттеджына байларның.

# Ядрәләр ярыла

Ядрәләр ярыла... Кешеләр
Кешегә ут ташлый еракта.
Төн буе яралар бәйләдем,
Мең кайттым шикелле урап та.
Мин, нәни бер кызчык, сискәнеп
Уяндым тып-тыныч ал таңда.
Ядрәләр ярыла торгандыр,
Кап-кара төтенлер ул анда.

Әткәм өчен курыктым...

Өемдә ядрәләр ярыла,
Күземдә ярыла ядрәләр.
Дөньяның нәкъ теге ягында
Җир-суны утларга төрәләр.

Сискәнеп уяндым ал таңда,
Уйлардан арынган уңайга:
— Сөеклем, — дидем мин, —
бик ардым.
Бер төнем сузылды ел-айга.

Ирем өчен курыктым...

Бүген дә дары исе һавада,
Туктаусыз ярыла ядрәләр.
Ярамас, димиләр, җан кыю,
Экраннар һәр өйдә — күрәләр.

Сискәнеп уянам ал таңда,
Айнымый дөм кара төненнән.
Югыйсә көч ала бу дөнья
Аналар күкрәге сөтеннән.

Улым өчен куркам...

* * *

Биләр җире тоташ каберлек, ди,
Баскан саен изге урыннар.
Монда хәзер башка халык яши,
Үлән утлый «каты борыннар».

«Изге чишмә» һәм «Хуҗалар тавы»
Түбәсенә кадәр күтәрә.
Килгән саен арткан әрнүләрем
Сагыш утларына этәрә.

Олуг калалардан көлләр калган,
Көлләр кала әле бүген дә...
— Изгелектән сибелеп гөлләр кала,
Гөлләр калсын иде бу илдә! —

Дип пышылдый Биләремне саклап
Шәһит киткән горур яшь кызлар.
Миңа газиз шул туфракта әнә
Мыркылдашып ауный дуңгызлар.

И Биләрем, и Болгарым минем,
И язмышым минем, и халкым...
Кемгә чүлмәк ватыклары — байлык,
Кемнәргәдер көмеш һәм алтын.

## Себердә

Саумысыз, Себер җилләре,
Исәнме, Себер җире!
Туганнарым көтәдер күк,
Мин дә бит килдем бире.

Мин дә бит татар баласы,
Газизе, бердәнбере.
Барыбыз да бердәнбер без,
Хәтер сау әле, тере!

Себердә дә татар шул без,
Себердә дә билгеле.
Тәрәзәләр яран гөлле,
Кашагалы, өлгеле.

Уңганлыкта, тырышлыкта
Алмаш юктыр, юктыр шул.
Без киләчәк тамырына
Шифа бирер чыктыр шул.

Монда төере милләтнең
Буталган каннарының.
Эзләренә басып килəм
Мин Себер ханнарының...

Ул эзләрдән күпме юл бар
Безнең тарих күзенә?
Ә йөрәктә күпме төен
Чишелә дә өзелә...

Өзелә дә ялгана шул,
Себердә уйлар изге.
Себердә татарлар исән
Һәм исән татар сүзе.

Туганнарым түредәй киң
Миңа да Себер түре.
Без һәммәбез бер татар шул —
Ыруның бердәнбере!

* * *

Сөлге тотып торучы юк юлларымда,
Иртә таңнан яшәү — бәйге,
яшәү — ярыш.
Көтмәгәндә сөрлектемме, әллә нишләп
Бүтәннәрдән артта калдым тик бер карыш.

Кызгану юк, сызлану юк. Мөмкинмени
Бер җылы сүз көтеп карау җиде ятка.
...Мин кайттым да шау чәчәктән
сөлге чиктем
Сабантуйда иң азактан килгән атка.

## Изге Биләрдә

Изге Биләр, Олуг Биләр.
Хәтер йөри иңләп-буйлап.
Шәһәр беткән, туфрак калган,
Ташлар калган уймак-уймак.

Калган чүлмәк ватыклары,
Калган тимер ярчыклары.
Шул ук кояш калган монда,
Шул ук болыт, таң чыклары...

Йөрәкләрне ничә гасыр
Телем-телем телеп була.

Елыйм дисәң, бу язмыштан
Елый-елый үлеп була.

Газиз халкым! Мең сынгансың,
Сыгылгансың, егылгансың.
Көлеп торган дошманыңны
Бәлаләрдән мең йолгансың.

Газиз халкым, өең янган,
Тарих буйлап жирең янган.
Тик кояшың калган бары,
Таң чыкларың, болыт калган...

Сине шулар саклагандыр,
Җан өргәндер тамырыңа.
Ышандыңмы, илләр кабат
Дәүләтле дип таныруна?!

И Биләрем, газиз калам!
Газиз туфрак, тирән ярам.
Тукта! Хәтер, Өмет белән
Җитәкләшеп кая барам?..

## Нинди ил бу?

Нинди ил бу? Учагыннан
Кулы белән ут туткан?
Аналарга утлы күмер
Кисәүләрен йоттырткан.
Нинди ил бу? Янган мичкә
Тыгып, бала юаткан?
Үз өем дип, почмак бүлеп,
Үзен-үзе югалткан.

Нинди ил бу? Уттан тора
Тыныч чагы, күрәше.
Көне-төне, иртәгәсе,
Тарих тулы күз яше.
Нинди ил бу? Мәңге көткән
Яшьләр таммас минутны.
Күз яшьләре төшәр, әмма
Сүндерә алмас утны...
Шундый ил бу.

## Иман

Шул күкләр бу, мең кат сискәндереп,
«Сөбханалла» диеп дәштергән.
Әбекәем, күзгеләрне барлап,
Яшен күзләреннән яшергән.
(Ә шәһәрдә минем сискәнергә
Вакытым юк хәтта яшеннән.)
Сөбханалла — чәчләремнән сыйпыйм,
Сөбханалла — женнәр калмасын.
Чәчләремдәй караңгылык җирдә,
Ялкын гына ялмап алмасын.
«Сөбханалла» — тагын үтәр яшен,
Авылыма булмас берни дә.
Курку түгел, иман яши шулай,
Кош оясы сыман, һәр өйдә.

# Кызганам

Әй кызганам вакыт-вакыт
Халкымның хәләл көчен.
Җир астында күмер кискән
Бер телем икмәк өчен.

Иген үстерсеннәр диеп,
Чирәм күтәреп биргән.
Сөенгән дә соң маржалар,
Унганга тырыш ирдән.

Юллар салган, илләр салган,
Батып тир, кара эшкә.
Калай медальләр элгәннәр
Баһадирлыкка, түшкә.

Еллар үткән, гомер үткән,
Хәер, ни бар үтмәгән?
Үтмәгәне — гел бер телем
Ипи генә җитмәгән...

Әй кызганам вакыт-вакыт
Халкымның хәләл көчен.
Утка керә, суга төшә
Бер сынык икмәк өчен.

# Йөрәк сызлый

Әй сөенгән идек, «Азатлык» дип
Әйтә алган өчен урамда.
Адашыплар калды бугай ул сүз
Күз ачкысыз әче буранда.

Ни икәнен бик беләсе килеп,
Ни икәнен белми сөендек.
Ап-ак уйлар белән атлап киттек,
Хыялларда актан киендек.

Хәерлегә, диеп дога кылды
Карт-корылар, көннәр туганда.
Кул-аяклар сызлап сулкылдады, —
Юрадылар һаман буранга.

Без дә халык, без дә милләт, дидек,
Безне дә бер Ходай яраткан.
Һәм, яратып артык, бураннарның
Ачыларын юлга тараткан...

Ул бураннар куркытмады, юкса
Мәйданнарда милләт кайнады.
...Йөрәк сызлый. Димәк, безнең кебек
Уянганнар бардыр кайдадыр.

## Сорадылар

Ирек даулап дулкын ярга аткан
Ташлармы соң болар, балыкмы?
Сорадылар:
— Кырым татарлары
Белән сез соң бер үк халыкмы?
— Әйе, — дидем мин дә, —
без бер халык,
Кан кардәшләр, — дидем, — туганнар.
Әйтерсең лә шушы сүзләремнән
Бер-бер дәһшәт көтеп торганнар.
Гаҗәпләнеп шомлы карадылар,
Карадылар бераз ят итеп.
...Ялтадагы диңгез дулкыннары
Югач, ярлар калды ялт итеп.

Дулкын ярсып ярга аткан ташмы,
Кабырчыкларлармы бу, балыкмы?
Диңгез буе. Кырым. Хәтта дулкын
Хәтерләтә безнең халыкны.

## Акты юл

Мин, атап, гөл өздем
Илемнең
Язмышын язышкан ир-атка.
Карасам, салават күпере
Сузылган бакчамнан — зиратка...

# Казаннан кайткач

Синдә, Казан, булыр иде кебек
Бераз гына җиңел сулап та.
Кол Шәрифең унда каршы алса,
Чиркәүләрең кала сул якта.

Синнән минем күңел аерылмаган,
Киткән еллар сыймый дистәгә.
Азаннарга оеп барган җаным
Чиркәү чыңнарыннан сискәнә.

Әллә ничек, мин узасы юлга
Шомлы карый кебек тәрәсе.
Ә бәлки бу сукмак, тарихларны
Тыңлап, гыйбрәт алу дәресе?..

Их, студент чакта урамнарга
Яшьлек булып керә идек без.
Баумандагы чиркәү бинасында*
Еракլыкка сикерә идек без.

Казаннарда — илем, дияр кемнәр,
Тарихыңны ятлар учлагач.
Сикереп кенә ерак төшеп булмый,
Канатланып җаның очмагач.

Үзгәргәнсең, Казан! Бик гүзәлсең,
Тәреләрең арткан үзәктә.
Бәргәләнә җаным... Килми калмам,
Китә алмам куллар изәп тә.

---

* КДУ студентларының физкультура дәресләре совет чорында спортзал итеп үзгәртелгән чиркәү бинасында үтә иде.

Без күбебез читкә сикергәнбез,
Шактый читкә изге Казаннан.
Илһам алыр Казан азаннан да,
Бер узар күк язмыш язганнан...

Сагынганмын, Казан! Җырлап булмый,
Елап булмый хәтта үкереп.
Һавалардан җиргә төштем әле,
Җиргә төштем гүя сикереп.

* * *

Мин барыбер читкә китә алмам,
Чит җирләрдә олтан булып булмас.
Үз илемдә солтан булып булмас,
Барыбер аны ятим итә алмам.

Мине барыбер читтә чит күрерләр,
Ят җирләрдә җирсү нигә инде?!
Әй туган як, бер җыр көйлә инде,
Ачык тәрәзәдәй бит күңелләр.

Язмышларны язып булса алдан,
Яшен булып кына яшәр идем.
Үз күгемдә генә яшьнәр идем,
Мин барыбер читкә китә алмам...

* * *

Дөнья матур!
*Һ.Такташ*

Килен булып төшкән мәле кышның,
Җил очырта ап-ак күлмәген.
Мин үләрмен кебек иде быел,
Тунсыз көе тагын үлмәдем.

Кул әрнесә, тешләремне кыстым,
Җаным тунса, ирен тешләдем.
Ак карлардан учак тергезәләм, —
Килен булып бүген төшмәдем.

Кышлар салкын, диеп, күпләр үтте,
Ачы, усал, диеп, зәмһәрир.
Ә язмышлар, безгә ни язса да,
Ни сызса да, үзе мөхәррир.

Ах, үзебез язар идек тә сон,
Хаталанмас идек — гыйлем аз.
Карлар ява, сибелеп карлар ява,
Һәр бөртектән ява күпме наз!

...Нәселгә бер түрәсе дә юк шул,
Кул сузардай юк шул кеме дә.
Дөнья матур!
Кемгә рәхмәт әйтим икән кышның
Килен булып төшкән көнендә?!

# *Хәерле рух*

Айлык керем кеше башына биш мең сум тәшкил итмәсә, бу — гаилә хәерчелекнең аргы ягына чыккан дигән сүз.

*Газеталардан*

Хәерче рух, хәерче тән,
Моннан саклар юрган юк.
Кесә бушап торганда да,
Куллар сузып торган юк.

Хәлле булып караган юк,
Елак булып караган.
Ярлы түгел, бай да түгел,
Йөрим ике арадан.

Чут төймәсе дә тарткан юк,
Бармак житә, дисәк тә,
Үтә хәерче икәнбез
Дәүләт салган исәптә.

Кайгыртalар соң безне дә,
Бар соң чутлый белгәннәр!
Әзме хәерче икәнен
Белмичә дә үлгәннәр?!

Хәерле рух яши шулай,
Гасырлар кичә-кичә.
...Ә хәерче икәнемне
Үлә алам белмичә.

# Юл кичүе

Ашыгудан, юлда кешеләрне
Ера-ера үттем бу төндә.
Кулын сузып теләнчеләр калды,
Яшьләр калды зәңгәр төтендә.

Чынлап калды сыра шешәләре
Кичүдәге кибет эчендә.
Суык төндә, их, арканы терәп
Җылынасы дөнья мичендә!

Газлы заман һәм төтенле заман,
Авылда да мичләр сүтелгән.
Безнең чынлык әкиятләргә күчкән,
Әкияти еллар үтелгән.

Адымнарга тизлек күрсәтергә,
Йөрәкләрдә очар ук ята.
Кемне сыра йә тәмәке кибете,
Кемне теләнчеләр туктата.

Сөйләнгән сүз, вәгъдә, мәгънә, антлар —
Яшьләр барсын төргән төтенгә.
Илсезләр дә, җирсезләр дә сыйган,
Өйсезләр дә сыйган бу төнгә.

Кемгә эндәшсәм дә, ишетмәсләр,
Мин гади бер үтеп баручы.
Бу кичүдән унга чыгып була,
Сулга алып чыга бер очы...

Бер акыллы затың бармы, дөнья,
Уң һәм сулны аерып бирерлек?
...Иркен сулап, өр-яңа бер әкият
Тыңлыйсылар килә бирелеп.

## Бизмәнче карт

Базар юлы. Бизмәнче карт.
Бии үлчәү телләре.
Яфрак куып менгәнмени
Ябык заман җилләре.

Яшәгән дә соң кешеләр
Үз хәлләрен белмичә.
Бизмәнче картны күрмичә,
Иң гаҗәбе — үлмичә.

Бар төрлесе. Җаны белән
Бизмәнгә сыймаганы.
Бар сыен та, сыйганлыгын
Танырга кыймаганы.

Күзләрен биетеп ала
Бизмәнче тере генә.
Бу, бәлки, бар һөнәренең
Җитмештән бере генә.

Читләп үтә алмас аны
Татар, урыс, чегәне.
Картның юк менә бер кат та
Түрәләр үлчәгәне.

Ничек әйләнмәгән дөнья,
Кемнәр галим булмаган?!
Түрәләр үлчәр бизмәннәр
Уйланып табылмаган...

Тормыш кебек кайный базар,
Бизмәнгә күзен салып.
Чал тарихтай сакаллы карт,
Үлчәнә гади халык...

## Һәйкәлләр

Танып булмый бүген заманнарны,
Табып булмый үткән эзләрне.
Һәйкәлләр дә алмашынды хәтта,
Батырлар да хәтта үзгәрде.

Дошманлык та, дуслыгы да үзгә,
Һәрьяклап ут. Тарта ул утлар.
Тик Чулманда һаман шул ук сулар,
Тик күкләрдә шул ук болытлар.

Һәйкәлләргә баш июләр үтте,
Кат-кат чакрымлаган юл барып.
Корыч атлар гүя язмышларның
Ялгышларын атты кубарып.

Әллә тарих, әллә киләчәгең —
Әй замана, кайсы ялгышың?
Һәйкәлләрдәй гүя, газиз халкым,
Актарылып ята язмышың.

* * *

Керфеккә эленгән төн нуры,
Илгизәк хисләрем арымый...
Чайкала суларда күләгәм.
Һәм мәчет өстендә ярымай
Тибрәлә Чулманда. Ул мине
Су айкап юата шикелле.
Яр тулы учаклар ягылган,
Урыны калган да, һәм көле.
Ә елга ашкына еракка,
Су китә, гомерләр югала.
Ярымай чайкала Чулманда.
Су китә... Ә денле ил кала.

# Таң

Без Бишенче елны беркөнне
уяндык таң белән.

*Г.Тукай*

Кабатланган иде ул таң
Гасырның азагында.
Ирекне йоталган кадәр
Капсаң да аз чагында.
Ул таңнарда, бәйрәмгә дип,
Калачлар салдык инде.
Теләгән кадәр барыбер
Кабалмый калдык инде.

Кабатланмас янә ул таң,
Бик килсә дә күрәсе.
Килсә дә баш очыбызга
Кояш итеп эләсе.

Нәкъ без көткән таң иде ул,
Яп-якты иде менә.
Мондый таңнар килсә-килә
Гасырга ике генә...

# Чигенүләргә кызыгу

Ах, сездәге Хөрлек! Ах, ул Ирек!
Дәүләтләргә сыймас ирекләр.
Ул иркенлек бик күпләрне алдар,
Бик күпләрне сүздә эретер.

Ах, сездәге Хөрлек! Без богаулы,
Җан богаулы, күрче, каһәрне!
...Мин халкыма ирек теләр идем
Чигән итәкләре кадәрле...

Бер җилфердәп үтсен иде шулай,
Тарих урамыннан урап та...
Һәм кызыгып калсын иде дөнья,
Бу халык, дип, китәр еракка.

Ах, сездәге Хөрлек! Ул азатлык
Янә калкыр, яшен бәрсә дә.
Дәүләтләргә ирек кирәк, кирәк!
Ә иреккә дәүләт нәрсәгә?

## Бөеклек

Гомер бакый халкым бөек булган,
Язмыш аны кат-кат алдаган.
Чит халыкның чиркәүләрен ишеп,
Ташларыннан мәчет салмаган.

Ямьсез сүзләр бик еш ишетсә дә,
Яман сүзләр үзе әйтмәгән.
Коръән тотып кулга, һәрбер затын
Бергәлеккә дәшеп әйдәгән.

Татар башы Идел тулып аккан,
Татарныкы — Идел, димәгән.
Минеке, дип, капкасыннан кергәч,
Кунак иткән, әмма тимәгән.

Бик күпләрне татар сабырлыгы
Бүген дә бит сала шикләргә.
Чик булмәгән халкым! Юк, татарны
Сыйдыруы кыен чикләргә.

Бетсен, диеп, утка аткан чакта,
Калкып чыккан янә сулардан.
Гомер бакый халкым бөек булган.
Бөеклеге, бәлки, шулардан...

# Кибеттә

Эндәшкән идем:
 — Сеңелем,
Бер ак күмәч бирегез!
— Тәрҗемә итә беләме
Арагызда берегез?..
Әйтерсең бәрәңге булып
Тәгәрим кайнар көлдә...
Әтием кырлар тотырып
Икмәк үстергән телдә
Сорадым ласа! Мин кабат
Дәүләтсез, илсезмени?
Татарга тылмач кирәкме,
Ул гел билгесезмени?
Тоткарланып калды чират
Минем аркада гына.
...Күз алдымда әткәм кыры
Бер шаулый да бер тына.
— «Икмәк» сүзен өйрәнгәнгә
Булыр иде мең савап!

Кайттым да утырам менә
Үле телләрне санап.
Кызганасы микән? Белмим.
Халык югалган. Тел дә.
...Бәрәңге булып тәгәри
Йөрәгем кайнар көлдә.

# Әрни

Шаһгалиләр үлеп беткән дисәм,
Исән икән әле, тереләр!
Мескен халкым тирәсендә гүя
Өер-өер йөри бүреләр.

Дошман безнең үзебездә яши,
Урыныбыз юк читтән эзләргә.
Гаҗәпләнеп тормыйк инде кабат
Суга-суга учны тезләргә.

Бүген булса, бүген Шаһгалиләр
Иярәчәк Явыз Иванга.
Халкым әле «СПИД-инфо» укый,
Кырын ятып кына диванга.

Менә шулай җылы диваннарда
Милләттәшләр көн дә эрерләр...
Шаһгалиләр исә, үзебездән
Дошман эзләп, озак йөрерләр...

* * *

Чишмәләргә челтерәүләр кирәк,
Ә утларга кирәк гел дөрләү.
Кошка — сайрау,
миңа — халкым моңын
Үземнеке итеп кадерләү.

Юл газабы — гүр газабы, диләр.
Ут әйткәндер сүнеп барганда.
Кош әйткәндер, очар канатлары
Диңгезләргә тиеп алганда.

Мин дә юлда, мәңгелек бер юлда,
Халкым моңын илтәм халкыма.
Чишмә челтери, утлар —
шушы монда,
Шушы монда кошлар талпына...

## Ватаным

— Кызым бар!
— Кыз туды!
Әткәмнең йөзедәй
Яктырып балкыган ал таңым.
Шуңа да,
Әнкәем биләүгә төргәндә, мин сине
Кояш дип белгәнмен, Ватаным.
Әле дә иң башлап тавышым ишеткән
Зәңгәрсу, тын күгем beләнмен.
Шуңа да,
Жанга күк киңлеге иңгәндә, Ватаным,
Мин сине һава дип белгәнмен.
Тәпиләп киткәч тә, сөенеп куйганмын,
Тойганмын жиремнең ныклыгын.
Шуңа да,
Ныгыган саен, мин ныграк сизгәнмен
Туфраксыз — Ватанның юклыгын.
Ә хәзер буй кызмын үз туган жиремдә,
Жавапны шулкадәр тиз табам.
Барыбер:
— Ватан ул ни? — диеп сорарсыз,
бәлки, сез,
— Туфрагым, Кояшым, Саф һавам!

## Йөк

Йөгерә-йөгерә сукмаклардан үтәм,
Сукмакларым миңа йөгерә.
Исе китеп карап тора дөнья
Иңнәремә салган йөгенә.

Күзләремдә сабый кояш уйный,
Өлкән чагын, хәер, күрмәдем.
Җете кызыл тиз уңучан була,
Алсу гына кигән күлмәгем.

Фәкыйрь, димим әле бәхетемне,
Сукмакларым миңа йөгерә.
Өметемне җигәм бу дөньяның
Иңнәремә салган йөгенә.

## Туган телем

Мин шундый бер шигырь язмак булам,
Бөтен кеше укып аһ итәрлек.
Дөнья кара булып күренгәннең
Кайгы пәрдәләрен ак итәрлек.
Мин кайчакта шагыйрь булмак булам,
Кул сузмакчы булам йөрәкләргә.
Ятимнәргә, бәхет тимәгәнгә,
Албастыга, иблис, өрәкләргә.
Мин сүзләрдән энҗе тезмәк булам,
Гүзәллеге ашып сыман чиктән.
Юк, эзләнми ялтырамас һич тә,
Туган телем затлы мәрҗән икән.

## Шулайдыр

Изгелек чәчмәк булам да,
Яманлык булып кайта.
Сукмакларын бутыйм бугай:
Кайда ак, кара кайда?

Шатлык өләшмәк булам да,
Кайгыга төшә башым.
...Болытка әйләнер идем,
Күкләргә ничек ашыйм?

Бирәүгә саулык телим дә,
Бар гәүдәм кала чирдә.
...Янгыр тамган саен, чәчәк
Калкып чыга һәр җирдә.

Тамчысы саен гөл шыта,
Күктә яшәү кулайдыр.
...Болытка да ачулылар
Буладыр ул. Шулайдыр.

## Фирүзә

Җаның сау түгелне сизеп,
Үзгәрә калса төсем,
Гаҗәпләнмә. Асылташ мин —
Фирүзә минем исем.

Заманымның саусызлыгын
Яшимдер йота-йота.
Зәңгәр күкләргә карасам,
Җирдәге хыял тота.

Зәңгәр төс өстәмәк булам,
Атылып һавасына.
Ышанмаганнар ышаныр
Нурымның дәвасына.

Холкым, төсем фирүзә шул,
Тыныч та, алкын да мин.
Йөрәккә якында — кайнар,
Һәм боздай — салкында мин.

Үзәгемә яшерәм дә
Ятларның кара үчен.
Гүзәл бер бизәк буламын
Кадер белгәннәр өчен.

Бер җепләргә тезә тормыш
Һәр бизәкнең үз ишен...
Югалтма, дөнья! Асылташ —
Фирүзә минем исем...

## Туган якта

Каерылып әнкәй печән чаба,
Шулай чаба иде элек тә.
Мин ташыган булам кочаклап та,
Сәнәк очларына элеп тә.

Ир-егетләр дәшә каерылып:
— Алла ярдәм бирсен сезләргә!
Алсу җиләк. Хуш ис. Яшел болын...
Дөнья ямьсез түземсезләргә.

Эшкә түзем әнкәй. Әткәм белән
Тигез бүлеп, тигез күтәрде.
Күкрәүләрдә чалгы сабы белән
Терәп торыр иде күкләрне.

Алсу йөзле тукранбашлар бии,
Ә болыннар янә яшелдән.
Каерылып печән чаба әнкәй,
Ялгызлыгын кая яшергән?

Кирәк өчен түгел. Сыеры юк,
Бәрәннәре ике баш кына.
Печән чаба, балам күңеле, дип,
Әйләнмәсен юллар ташына.

Кайталмыйм шул. Печән вакытларын
Басып китә юллар тузаны.
Бар тузансыз юллардан да җәйнең,
Гомеремнең очып узганы.

Ә мин бүген сабый. Яланаяк
Печән җыям әнкәй артыннан.
Алсу йөзле тукранбашлар, күрче,
Мин эзләгән бәхет-алтыннар...

## Гомер

Ул ашыгып китеп бара иде,
Хыялына таба йөгереп.
Туктап калды, ап-ак алмагачның
Чәчкәсенә бител тигереп.
— Гүзәл кәләшмени! Ах, хыялым!
Ак хыялым минем бу, — диде.
Беренче кат аклык сискәндерде,
Тулган көне иде унжиде...

Ул тын гына атлап үтмәк иде,
Карашлары шундый сак иде.
Куенында, ап-ак биләүсәдә
Израп йоклый иде сабые.
Исерешкән җилләр коя иде
Алмагачның ап-ак чәчкәсен.
— Әнкәм чәчләредәй чал соң! — диде.
Ул яшь хатын — ничек дәшмәсен?

Ап-ак иде майның алмагачы,
Бик тынгысыз кичте бер төнен.
...Үтеп барган чакта, күңелдән ул
Барлап куйды ап-ак кәфенен.
Таягына таянып лар торды,
— Рәхмәт, тормыш! — диде аннан соң...
Шул әбидәй тынды ак алмагач,
Урлаткандай соңгы алмасын.

* * *

Алмагачка бик авырдыр:
Алмалар коелырмы?!
...Алмадай серем бүлешер
Дусларым җыелырмы?

Коелганнар да алмалар,
Җыелганнар алмалар.
Ятлар җаен таба белә,
Эч серемне алалар.

Сүзләремне ничек җыйыйм,
Җил кая да, сер кая?
...Алмагач та әллә нигә
Саргая да саргая.

* * *

Карлар ята нарат түбәсендә,
Кәүсәләрдә, өстә, югары.
Ә түбәндә ап-ак көртләр ауный,
Үтә шуннан сукбай юллары.

Шул карларны таптап, этләр уза,
Атлар сыгылып уза һәр йөктән.
Карлар ята нарат кәүсәсендә,
Түбәннәргә карап биектән.

Уйлый алар: ярый җирдә түгел,
Ярый әле без, дип, югары.
Ярый Ходай насыйп итмәгән, дип,
Булуларны сансыз юл кары.

...Уйлар очы йомры йомгак инде,
Көннәр генә язга авышкан.
Җиңүләрне бәйрәм итәр кояш,
Кем отылыр шушы алыштан?

Ылыслардан елап тамчы тама:
— Без лә идек, — диеп, — нигезле...
Ә юлларда әле ак кар ята,
Нишләтәсең — дөнья тигезле.
Вакыт-вакыт дөнья тигезле...

## Чит тәрәзләр

Чит тәрәзләр күзәтергә яратам мин,
Тезелеп-тезелеп үтә алар күз алдымнан.
Ап-ак җиләк тамып тора. Карашымны
Ак каеннар адаштырып бер адымнан.

Чит тәрәзләр күзәтергә яратам мин,
Буран оя корганы бар, карлылары.
Һай, бу килен уңмагандыр, мескен бала,
Саркып чыккан пәрдәсенең сарылары.

Ялгыз карчык карап тора минем юлга,
Кар өстенә сибелеп төшә сүрән якты.
Урамда төн. Янә пәрдә артларына
Йомарланып күпме язмыш кереп ятты.

Карашымны кисеп ала ак бөртекләр,
Һәммәсе дә хәрәкәттә, бар да тере.
Чит тәрәзләр җилдәй исә күз алдымнан,
Ә пәрдәләр... ә пәрдәләр төрле-төрле.

* * *

Дөнья булгач, төрле чаклар була,
Белмәгәннәр белми.
Кош та очмый, җил дә исми кайчак,
Йөрәгемне телми.

Ак каеннар яктылыгы таңдай
Күзләремә төшә.
Җылы, йомшак эзләремә ятып,
Җир җиләге пешә.

Төннәр буе ялсыз, керфек какмый,
Ай нурында йөзәм.
Карлы таудан көлеп-көлеп торган
Умырзая өзәм.

Җәйге челләләрдә яңа туган
Хыялларым туңа.
Өметемдәй кояш чыга һәр таң,
Яшим менә шуңа.

## Теләк

Күзгә кояш гүя мина тәрәзәдән
Кер әләргә баулар суза. Кер әләргә!
Әллә нишләп жинел булып китте минә,
Мохтаж чагым иде якын күрүләргә.

Әйтмәгезче, туфан кубар, жил чыгар, дип,
Давылларга хатын-кыз кер әләмени?
Кояш әнә тәрәзәдән баулар суза,
Мина аяз көн килэген беләмени?!

Ап-ак итеп биләүсәләр юып элдем,
Бар жиһанга ачылсын ла серле серем:
Жил-давылдан сакла, дөнья, сабыемны,
Минем изге теләгем ул — юган керем.

## Капка

Тузаннарга баттым янә,
Күзгә жил каккалармы?
Шакып кына керәп булмас
Бу биек капкаларны.

Ишетмәсләр, аларгамы
Ятлар көен көйләргә?!
Тузанын да читләр сөртә
Биек-биек өйләрдә.

Биек-биек капкаларны
Бәхет ачалмый узган.
Яшәү тамырына төшсән,
Кемнәрдер чынлап тузан...

Тузаннарның туганы юк,
Күршесе юк, якыны.
Фирүзәсе, көмеше юк,
Зөбәрҗәте, алтыны.

Тузаннарга батты уем,
И язмышым, каккала.
Йозак салма, бикләр куйма
Миңа тигән капкаңа.

* * *

Мин ашыгып еллар буйлап узам,
Гомер буйлап узам йөгереп.
Аһ, көннәрем шундый әрсез минем,
Терекөмеш кебек йөгерек.

Тотып алып булмый, җыеп булмый,
Сыйдыруы кыен вакытка.
...Терекөмеш кебек югалганнар,
Калыр өчен башлар ватып та.

Бар да фани! Юк, иртәгә әле
Өр-яңадан эшем өстәлә.
Бүген менә терекөмеш кебек
Каләм бии минем өстәлдә.

И тарала уем, төн карала,
Көтмәгәндә җаным үртәлә.
Терекөмеш кебек таралма тик,
Таралмале, дөнья, иртәгә.

# Без яшь чакта

Без яшь чакта кояш якты иде,
Шау сиреньле язлар көтә иде.
Күзләр җитсә, шаулап кыр казлары
Җанга кагып очып китә иде.

Яшь чакта ул һәр тал җырлый иде,
Капка төптә, безнең урамнарда.
Әбекәйләр бәбкә саклый иде,
Тилгәннәргә бирми урларга да.

Ә без менә газиз әнкәйләрнең
Төн йокысын урлап кача идек.
Тальян гармуннарга ай биетеп,
Ал таңнарга капка ача идек.

Ай да якты иде, нуры белән
Күңелләргә кат-кат урала иде.
Безгә кушылып көлә-көлә, күктә
Төннәр буе биеп тора ала иде.

Бар да гүзәл иде без яшь чакта,
Без яшь чакта хисләр ихлас иде.
Бик тә җитди сыман идек лә без,
Җилбер җилләр бераз иләс иде.

Мин яшьлеккә кайтыр идем сыман,
Кыр казлары кайтса туган якка.
Җанга очып төшә иде алар,
Язлар җиткү белән без яшь чакта...

## Төзелештә

Биеклектән биеклеккә ашып,
Кемдер төзеп, кемдер бизәп тора.
Ә кранчы егет өстән генә
Сөйгәненә куллар изәп тора.

Җиденче кат күктә, шул ак өйдә
Туй итәрбез дигән исәп тора.
Ә горур кыз юри күрми аны,
Ихлас кына өйләр бизәп тора.

Ул горур кыз юри күрми аны,
Тик күренеп зур йорт-бизәк тора.
Сөюләре шәһәр тергезерлек, —
Ике йөрәк бердәй сизеп тора...

* * *

Мин язам үзем булып та,
Язам бүтәннәр булып.
Киләчәк булып язам мин,
Язам үткәннәр булып.

Йөгерәм язлар булып та,
Тынам бураннар булып.
Йөрәгем бүген өзелгән
Яфрактай сулык-сулык.

Көчем суыра. Ә мин язам
Җәйге офыкка карап.
Тик үзем булып калам мин —
Булмас һәркемгә ярап.

* * *

Ничә яшь, дип сорамагыз миннән,
Кайбер көнне унсигездә булам.
Бөреләрнең якты күзләренә
Кояш нуры сыман сибелеп тулам.

Биеп китәм күңел кырым буйлап,
Кукчәчәкләр җыям кочак-кочак.
Бөтенесе мине дәшеп тора,
Бөтен галәм миңа янар учак.

Ничә яшь, дип сорамагыз берүк,
Исәпләргә салсаң, бүген — утыз.
Тәҗрибә аз, узар юллар урау,
Ялкын булып янам кебек утсыз.

Ә кайчакта, төнге күбәләктәй,
Очып-очып үтәм ут тирәли.
Тоймыйм үзем: учак җылытамы,
Канатымны әллә көйдергәли.

Ничә яшь, дип сорамагыз, зинһар,
Йөзне узып киткән бер карчыкмын.
Табигатьнең татлы җимешедәй,
Кыйпылыплар төшәр бер ярчыкмын.

Йөз катлы уй катламына төреп,
Зур дөньямны торам мин кочаклап.
Тагын мең ел, көнгә якты өстәп,
Ялкын сибеп янар бар учаклар.

Синең дә әле мең яшисең килер,
Күзләремә минем текәл генә.
Ә яшемне сорамагыз берүк,
Әйтеп бирә алмам төгәл генә.

## Күмер

Янган, диләр, беткән, диләр,
Калган, диләр, күмергә.
Ошаталар шул күмерне
Үтеп киткән гомергә.

Гомерләрнең мәңгелектә
Кала алыр мәле бар.
Күмернең дә самоварны
Жырлатырлык хәле бар.

## Яңа моң

Баскан жирләремдә тамчы моңы,
Утрау булып монга камалыр бит.
Кыш рәнжеше — бозлы сөңге әнә,
Йөрәгенә язның кадалыр бит.

Кадалды да сынды иң соңгысы,
Телсез калыр дисәм, дөнья тып-тын.
— Шауלармын... — дип, бөре күзен ачты,
Һәм яралды жиргә өр-яңа моң.

* * *

Түтәл тулы суган тузгып ята,
Без ташыйбыз аны алмашлап.
— Бәйләм-бәйләм тезеп үрәлмәгәч,
Кияүгә дә сезне алмаслар...

— Кияүгә без бармыйбыз да әле!
Күрше әби көлә:
— Барырсыз. —

И балалар, әле бу гомердә
Суган үрә-үрә арырсыз...

Менә шулай башлау кирәк аны,
Тигез итәр өчен бәйләмне.
Бездә өмә. Бездә кызлар бүген.
Көздә тормыш тоташ бәйрәмме?

Әбекәйнең тигез бәйләмнәре!
Күзне ертып керә ачысы...
Көзге түтәл. Айлы озын кичләр.
Суган тәме сеңгән аш исе...

Күрше әби көлә:
— Турыгызга
Кемнәр килгән, дисәм, һай, тилгән...
Берәм-берәм туйлар үткән. Еллар
Суган бәйләмедәй сүтелгән.

Бер биләмә суган тузгып ята.
Кемнәр белән миңа үрәсе?!
Кайда икән күрше әбекәем,
Якты түтәлләрнең түрәсе?

Тирә-юньдә җилләр тузгып ята:
— Кияүгә дә инде алмаслар...
Якты көзләремә суган тәме
Сеңеп кенә барган алмашлап.

Яшәү серләренә төшенәлмим,
Күрше әбекәем, син белгән.
Хәтеремә гәрәбәләр төсле
Бер биләмә суган сибелгән...

## Хатын-кыз

Көтәбез шул, гомер буе учта йөртер
сөйгән яр, дип,
Көтәбез шул, гомер буе саклап торыр
бәхет бар, дип,
Без — хатын-кыз.
Куанабыз, дөнья буйлап дәвамыбыз
килгән өчен,
Яшәү өчен ана булып, тыныч күкләр
күреп кичен,
Без — хатын-кыз.
Ышанабыз, улларыбыз илгә берәү
булырлар, дип,
Кояш сыман, бар дөньяга якты өстәп
торырлар, дип,
Без — хатын-кыз.
Теләк телибез, Ходаем, бир ярдәм, дип,
илгә-көнгә.
Тынычлык бир, мәрхәмәт бир,
мәхәббәт бир, дип, һәркемгә,
Без — хатын-кыз.
Һәм уйлыйбыз: гомер буе баламны,
дип, бәхет көтә...
Көтә белү — олы бәхет.
Үзебезгә шул да җитә...
Без — хатын-кыз.

## Әнкәй кайгысы

Анламадым, әнкәй никтер сүзсез иде,
Ул көн анын күнелкәе күзсез иде.

Сиздем генә, мин сердәше булалмадым,
Нәни жаным белән әрнеп туалалмадым.

Ияртмәде, китте әнкәй. Йә, кем яклар?
Йокла, диде, жәймәләрең коры,
пакьләр...

Ә шулай да күрдем бит мин шомлы өнне:
Бер йолдызын ияртмичә килгән төнне...

## Кайтаваз

Сызгырасым килде. Егетләрчә!
Авылымның мин бер кунагы.
Булдыксыз, дип,
пышан-пышан килеп,
Карап торды сәрби куагы.

Сызгырырга оныткамын, күрче,
Телем гүя авыр кургаш сын.
Әбекәйләр тәмләп төш күрәдер,
Тәрәзләрдә ник бер ут булсын!

Әй, малайлар, кызлар,
ник дәшмисез?
Мин бит кайттым сезне сагынып!
Элеккечә, сезне көтеп торам,
Сәрби куагына сарылып.

...Сәрби миңа сыбызгылар суздды,
Мин сызгырттым:
кызлар, чыгыгыз!
Хәтеремә якты аваз булып
Кайтты бары бала чагыбыз.

## Ташлар

— Мин мәңге гашыйкмын!
Әй, дулкын, килсәнә!
...Шат диңгез ташларын
Тутырдым кесәмә.

Ул ташлар салават
Күпере төсендә.
Әйтерсең чын түгел,
Бу диңгез — төшемдә.

Йөгердем яр буйлап,
Нишләргә белмичә,
Дулкынны кочтым мин
Шатлыктан, бу — кичә.

Ә бүген диңгез дә,
Ташлар да юк кебек.
Күзләрем күрмиме,
Уралам ут кебек.

Дулкынны кочтым мин
Шатлыктан, бу — кичә.
Ә бүген, сагынудан
Нишләргә белмичә,
Бушаттым кесәмнән
Ташларның барын да.
Аларга рәхәттер
Бары үз ярында...

## Исән чакта

Буш читлекле алларымнан үтсә,
Мәче юлны киссә — шикләну юк —
Башка төшми хәсрәт, кем көткән?!
Ә хәтергә көннәр ертып булмас,
Утка ягып булмас
Кара календарьлар беркеткән.

Трамвайда бер бәхетле билет!
Үзгәртте дә куйды, очып йөрим,
Җилләр ерып барам, җил егып!
...Шифаханә тәрәзәләреннән
Кул изәде берәү,
Чабып узганыма кызыгып...

## Көнбагыш

Давыл узган, тузан тузган бу җирдә,
Сыгылса да, сынмаган ла ул бер дә.
Япа-ялгыз, гап-гади бер көнбагыш
Миңа гыйбрәт. Табигать өчен табыш.

Давыл узган, әрнүләрен кем белгән?
Җир төсендә җимешләре өлгергән.
Кояш сыман чәчәк биргән тормышка,
Бер көнбагыш юкса карап торышка!

## Усак

Айны сары толымыннан
Тотып алам, дигәндә,
Кискәннәр дә аударганнар,
Башы күккә тигәндә.

Алмаштырганнар «утын»га
«Усак» дигән исемен.
Очып-очып ярылган ул
Мин, дип, йолдыз ишемен.

Җылы калдырып китә ул
Кешеләргә бер төнгә.
Йолдызларга менеп бара,
Әйләнгәч тә төтенгә...

## Яшь ана

Кояштан да якты итеп елмайды ул, аннан
күкрәгенә кысты сабыен.
Бәхетемә гөлнең күзе тимәсен, дип,
Тәрәз төбендәге яраннарга
карап
пышылдады:
— Тизрәк чәчәк атыгыз!
— Тизрәк чәчәк атыгыз!

## Май шәфәгы

Мин тынлыкка сеңеп беткән идем,
Кем өемә афәт җибәрде?
Йөрәгемә ачык тәрәзәдән,
Көлтәләргә бәйләп, ут бәрде?

Баксам, таллар, ярлар шундый алсу,
Ярга ятып, кайнап, ком яна.
...Сабый чакта кулым пешкәннән соң,
Ялкыннардан җаным шомлана.

Аh, болытлар янып бетәр инде,
Сибелер дә калыр көл генә.
...Кузгалгандыр күктә ут хәтере,
Якынлашкач Җиңү көненә...

## Сәхнә

Гомер буе артистлана кеше,
Ирек куя сүзнең алтынына.
Илгә, көнгә яки, hичьюгында,
Ярар өчен ире — хатынына.

Тирләр тама, ялган яшьләр тама:
Артист булып булмый җиңел генә.
Тормыш — сәхнә, әйләнмәле сәхнә,
Әйләндерим, дисәң, җигел менә.

...Әйтәсемне әйтми кала белмим,
Үз башыма телем бәла төрә.
Яши белә кеше артист булып,
Миндәйләре сәхнә әйләндерә...

* * *

Яну серен утка өйрәтмиләр,
Суга — агу серен.
Өйрәтмиләр тауга мәңге горур
Кала алу серен.

Яшәү серен гел өйрәнә кеше,
Жаны-тәне саудa.
Белү кирәк: кеше бер үк мәлдә
Ут та, су да, тау да.

## Хат

Янгыр ява тышта. Минем бүген
Кулым ятмый бер эш эшләргә.
Тып-тып тама әнкәй сүзе жанга,
Ул тамчылар төрле төсләрдә.

Әнкәемнең хатын укыйм. Юкса
Юлын-юлга беләм күңелдән.
Һәр хәрефе жылы салкын көздә
Күз нурлары булып түгелгән.

...Дөнья шулай. Кайчак ашык-пошык
Укыла да читкә куела.
Күр, вак болыт булып килгән хаттан
Дога сыман сүзләр коела.

Моңсу рәхәтлегем тантанасын
Тояр өчен тик шул житмәгән!
Дөнья үзе тибрәлә күк бүген
Миңа бишек элгән сиртмәдә.

## Җиләк

Урманны чыкканда,
Корыган ботакка
Эләгеп калды да чиләге,
Юлларның тузанын
Ястык дип белепме,
Чәчелде әнкәйнең җиләге.

Әрнүен карурман
Яшергән чагында,
Төсенә моңсу бер шик керде.
...Юлларның тузанын
Бәхет дип белепме,
Сибелдек җиләкләр шикелле.

Тузаннан аралый
Әнкәйнең күз нуры,
Сакла, дип, баламны бөләктәй.
Юлларга чәчелдек...
Тормышка ямь кирәк,
Тормышка тәм кирәк җиләктәй.

## Сөенеч

Кышлар бүген ак көнемнең
Нигезе кук.
Мин үзем дә тәңкә карның
Игезе кук.
Ап-ак серле яшәешем —
Шушы урам.
Һәр бөртекнең сулаганын
Сизеп торам.
Мин үтәсе юл да җиде
Чаттан икән.
Чатта көткән сөенечем
Актан икән.

## Диңгез ярында

Диңгез төбе катлам-катлам тоздыр,
Кирәк түгел кабат өстәргә.
Эретергә теләп, дулкыннары
Сикермәкче була өсләргә.

Диңгез, диңгез! Җәрәхәтле чакта,
Тозлар тигән чакта ярага,
Мин үзем дә синең дулкыннарны
Салмак булам ике арага.

Диңгез, диңгез! Чара табу кыен,
Вакыт дигән дәва барында.
Синең хәлдә, сине уйлый-уйлый,
Кымшаналмый торам ярында.

## Күбәләк

Гүзәл җәйнең соңгы сәгатьләре,
Сабыр гына кереп бара көзләр.
Алсу җәйнең соңгы күбәләге
Учларыма кунды җылы эзләп.

Кайнар учларымда җәй эссесе,
Кайдан белдең моны, и күбәләк?
Йөрәгемдә әле җәйге чиллә,
Бүләк итим мәллә соң түбәләп?

Шушы көе көзгә кереп барам,
Гөлләр өши аяк очларымда.
Йөз күбәләк, мең күбәләк сыя
Учагыма — минем учларыма.

Быелгы көз никтер язлар кебек,
Гүя лаләләрдән юллар җәйдем.
Соңгы хыял сыман очты кинәт
Соңгы күбәләге гүзәл җәйнең...

## Актылык

Җилләр бүген агып-агып килде,
Җилкән корып ап-ак болыттан.
Беләм, янә яшен ташын чөяр,
Кемнәр көяр янә ул уттан?

Болыт белән җилләр агып килде,
Һай, күп лә соң матур килгәннәр.
Матур китүләре авыр! Авыр!
Аз, авыр дип көя белгәннәр.

Җилләр бүген агып-агып килде,
Җилкән корып ап-ак болыттан.
...Ә мин менә яшен яктысында
Уйдан туңган җаным җылытам.

## Соңгару

Һәр чәчәк саен ак карлар
Елмаеп карый.
Кашкарыйлардан кышка да
Бер адым бары.

— Гомер кыска, гомер кыска!
Искәртә карлар.
Көзге букет өзеп кала
Исендә барлар.

Гомер кыска... кашкарыйлар
Торалар көлеп.
Ак карларны күбәләк дип
Юана белеп.

Бик тә кирәк таң сызылу
Йә кояш бату.

Күбәләкләр күрү өчен,
Җәй чәчәк ату...

Туңа-туңа, кашкарыйлар
Торалар көлеп.
Соң булса да, чәчәк ата
Белгәнен белеп.

## Көзге

Елмаябыз. Кояш булып
Булмаса да көннәрдә.
Елмая күк мамык шәл дә,
Тирәләр дә, күннәр дә.
Башлардагы эшләпәләр
Килешә дә соң инде!
...Хәер-фатихалар булып,
Җиргә елмаю инде.
Елмайдың да, нидер булды,
Йөрим жил чәчен тарап...
Мин үземне күрдем, синең
Күңел көзгеңә карап.

## Чык

Күз алмаңнан бер чык өзелеп төште,
Сүз дәшәргә сиңа кыймадым.
Бу әрнүең шундый гүзәл мизгел,
Мин тыймадым сине, тыймадым.

Күз алмаңнан бер чык өзелеп төште,
Җир тетрәгән сыман мина да...
Унжидедә бик тә килешә ул!
Юаталмый торам шуңа да.

Аңлыйм, кыен: чык кургаштай авыр,
Керфекләрең сынып китәр күк.
Иртәгәдән кояш чыкмас кебек,
Һәм бу язлар бүген үтәр күк.

Сиңа кыен. Яшьлек гаепләме
Бер мизгелгә назын түккәнгә?
Күз алмаңнан бер чык тәгәрәде,
Мине алып китте үткәнгә...

Күз алмаңнан бер чык өзелеп төште...

## Аптырагач

Кешеләрнең бәяләре төшкән заман,
Шырпы башы хәтле хыял чынга ашмый.
Аптырагач, Мәскәү тарафына багып,
Ни булса да сатасылар килә башлый.

Намус, вөждан бәяләре төшкән заман,
Акча — хаким. Акча хөкем иткән заман.
Карак кәеф-сафа кора түр башында,
Тугры юлда йөргәннәрнең хәле яман.

Баксаң, минем сатар өчен бернием юк.
Ни көем юк, жыр сатарга, ни кием юк.
Намус, вөждан сатылмый, дип өйрәттеләр,
Шәп өйрәнгәч, аларына тиярем юк.

Ни булса да сатасылар килә, әмма...
Заман атлый кебек миннән башка гына.
Сатар әйбер эзләнеп тә табылмагач,
Энже сүзләр тезәм янә... бушка гына.

## Дәвам

Чакырулы кунак булсаң бары,
Урыннарың түрдә көтеп тора.
Урынсызлар күпме бу дөньяда!
Үтеп тора гомер, үтеп тора...

«Карурман»дай хәтта берәүләрнең
Мәңге җырланасы килеп тора.
«Карурман» — бер. Меңләгәнен дөнья
Көйгә салмый гына көлеп тора.

Кемгә кардан ап-ак сукмак ярып
Бер үтү дә кайчак җитеп тора.
Әмма язлар килә, карлар эри,
Гомер уза... Кеше китеп тора.

Дәвам өчен ничек борчылмыйсың?!
Ни әйтсәң дә, дөнья калып тора.
Алма булып алма, сиздермичә,
Үзәгенә орлык салып тора...

## Җил

Әйләндерер иде тегермәнне,
Тегермәне генә калмады.
Кубарылып, яу килгәндәй килде,
Куркытырга теләп каланы.

Курыктылар! Кемдер каршы басты,
Шик-шөбһәсен эчкә йотты да.
Эштәгеләр эштә белми калды,
Йоклаганнар калды йокыда.

Басылды җил, тынды давыллары,
Аңлады, бу — дөнья икәнне.
Көтә-көтә килгән иде юкса
Үз уңаен унай иткәнне...

Канатланып китмәк иде дә соң,
Тегермәннәр генә калмаган...
Дөнья кызык. Бик күпләрне шулай
Уйнар мәйдан биреп алдаган.

## Ике көч

Берәүләр уйлыйлар:
— Сикерсәм дулкынга,
дингезләр болганыр.
Берәүләр уйлыйлар:
— Чакмалар чаксаммы,
дөньяны ут алыр.
Берәүләр эндәшер:
— Сикермә дулкынга берүк,
су йотмасын!
Берәүләр эндәшер:
— Замана давыллы,
ут кына чыкмасын!
Ике көч көрәшер.
Дулкыннар үз холкын күрсәтер
диңгезгә.
Ике көч көрәшер.
Ут һәм су шикелле яшәеш тиңсезгә.

## Бәхет

*Чулпанга*

Сеңелкәем бөдрә чәчен тарый,
Гөлчәчәк ул көзге түрендә.
Минем белән бөтен сөйләшкәне
Бүген никтер бәхет турында.

Аяк очларына басып, яңа,
Зәңгәр күлмәкләрен тын киде.
Көзгеләрдән күзен ала алмый,
Бүген аңа бары унжиде.

Һәм шаркылдап көлеп куйды шундук,
Сүзләрендә шатлык уйныйдыр.
Үзе кебек матур булып, бәхет
Очып килә диеп уйлыйдыр.

Мин дә шулай көткән идем аны,
Өметләрем исә гел исән.
Юк, эндәшмим. Ышана алмас миңа,
Иң бәхетле чагың бу, дисәм...

## Гыйбрәт корбаны

Кайберәүләр, жәлләп, бүрегенә
Акча сала ничә тиендер.
Сузылган кул — аның өмете ул,
Юл кичүе — жиләс өедер.

Еламый да ул, көлә дә белми.
Соңгы көне сүнгән, сизенә.
Кемдер аның йөрәгенә баскан,
Кемдер баскан аның йөзенә.

Төшеп киткән шулай. Куллар сузып
Тартып алып булмас чоңгылдан.
Кеме генә юк, әй, бу дөньяның?!
Бер ул гына түгел егылган.

Ятагы иткән салкын баскычларны,
Урап-урап үтә кешеләр.
Төссез карашларын алларына
Таш түшәкләр итеп түшиләр.

Көчсез рухын салып таптый-таптый
Сындырганнар басып йөзенә.
Ә югыйсә кайбер ир-атларның
Ул торырлык булган йөзенә.

Кешеләрне гел күрми дә хәзер,
Билләһи бу, диләр, өрәктер.
...Бәлки, безне сынар өчен шулай
Гыйбрәткә дә корбан кирәктер.

* * *

Кемдер йолдызлар кабыза,
Кемдер шәмгә ут ала.
Кемнәрнеңдер гомерләре
Ялкын белән бутала...

Кемдер кабызган учаклар
Ялкынлый да, тына да.
Берәү шат үзе кабызган
Тәмәке утына да...

## Сәер заман

Тәти күлмәк хакында еш сөйләшәбез,
Искиткечрлек кызык заман
килеп җитте:
— Кайсы илдән? Ничә тәңкә?
Каян алдың?
— Хәлең ничек? — дип сорауның
тәме китте.
Базарларның кызуында
кызгандырмас
Матур күлмәк кию, беләм,
язык түгел.
Сәер заман килеп җитте, имеш, сүзләр
Шул ноктадан башланмаса, кызык түгел.

Ә дөньяга ялангач та килгәнбез ич,
Җылы иңдергән башлап кояш,
зәңгәр күге.
Әллә нинди сәер заман килеп җитте,
Тәнгә тигән тәти күлмәк җанга үги...

## Гөл өзмәгез

Гөл өзмәгез, күбәләкнең
Кунар оясы бит ул.
Үзен кайчак бөркет итеп
Тояр кыясы бит ул.

Табигатьнең матурлыгы
Өзелгән гөл ишеме?!
Күбәләкләр кунар гөлсез,
Ә без җирсез кешеме?

## Наз

Үргә менсәм, җилләре кул суздьы,
Суга төшсәм, дулкын күтәрде.
Урманнарга керсәм, сукмагыма
Яткан җиләк исне китәрде.

Баш очымда сайрар кошлар торды,
Ак каеннар барыр юлымда.
Алтын яфракларга күмелеп калды
Көннәрем дә, хәтта елым да.

Гап-гади бер яшәеше белән
Горурлана күңел, куана.
Шушы дөнья буйлап, Кеше итеп,
Назың йөртә мине, Җир-Ана.

## Зонтигым — сәхнә

Зонтигым — сәхнә. Тамчылар
Бии дә бии, тып-тып.
Яратмый да яшәп була,
Була шашып яратып.
Салкын һәм якты бу көнне,
Гәрәбә юлларымны,
Күзем күрмәгән һаваны
Яратып сулавымны
Сизеп тора көзге яңгыр,
Шуңа бии тып та тып.
Тузып беткән зонтигымны
Сәхнә иткән яратып.

## Кактус гөле

Кактус гөле энә-энә,
Дөя теше сынарлык.
Кактус гөле чәчәк аткан,
Чынмы, диеп сорарлык.

Энәләр эчендә чәчәк
Яралу ялгыш кебек.
Ялгыш түгел, кактус гөле
Нәкъ минем язмыш кебек.

* * *

Сәламемне алмый үтте түрә,
Түрәләргә бар да сәлам бирә,
Диюедер.
Бәлки, бөеклеген
Күрсәтәдер шулай ара-тирә.

Сәламемне алмый үткәннәргә
Көенмимен инде, эчтән көләм.
Түрәлекнең мәңге түгеллеген
Белми йөргәннәрен яхшы беләм.

## Көзге яфрак

Нигәдер бөре чагыңны
Сагынасыңдыр кебек.
Ачы җилләр ябырыла,
Җепселең саен кереп.

Мин өтәм, дия суыгы,
Мин өзәм, дия җиле.

Көзге каен, ялгыз яфрак...
Ишле көз тәмам тиле.

Җилләре дәшә түгелме,
Агачын, диеп, сындыр.
Син дә бит язлар түрендә
Кадерле булгансыңдыр...

Яфрак булып ачылгансың,
Тоеп илдә бернне.
Тын алмый җәйләр тыңлаган
Сөйләп бетмәс серне.

Яз китерер идем сиңа,
Тик нишлим соң, иккүзем!
Табигатькә каршы барып
Булса икән берүзең.

## Күчтәнәч

Күчтәнәчсез киләләрмени?
Бөтенләйгә күчеп килсәң дә.
Җыр ни ул, дип көләләрмени?
Малың күп булса да кесәңдә.

Күчтәнәчсез киләләрмени?
Яздан — бөре, җәйдән — кузгалак.
Кар да бүләк. Беләләрмени?
Җырлый юкса ул да кузгалып.

Күчтәнәчсез киләләрмени?
Байлыкларың торсын бер кырда.
Җырны тыңлый беләләрмени?
Яз, көз, кыш та хикмәт ул — җырда.

## Май салкыны

Өшеп утыра куаклар,
Тамчылар эчә-эчә.
Өшеп утыра нәркисләр,
Яз кояшын күрмичә.
Өшеп сөйләшә кешеләр:
— Үтмәс салкын, ах, җаным!
Күр, нәркисләр — нәни генә
Кояшы һәр бакчаның.

## Туган йортымда

Туган нигеземдә ай да якты,
Йолдыз коелып тора өстемә.
Татлы уйларымнан бүлә-бүлә,
Бала-чага этләр өстерә.

Шулай уйный алар, шау-гөр килеп.
Этләр дә бу җирнең баласы.
...Мин китәсе юллар минут саный,
Их, бер көнгә тагын каласы!

Иярә дә китә хыялларым,
Коя-коя энҗе чыкларны.
Бала чакта мин дә белми идем
Чит җирләрдә кояш чыкканны...

Туган йортым тәрәзәсе якты,
Хатирәләр — тирән кое ла.
...Әткәм-әнкәм кабат чәй куйганнар,
Өсләренә йолдыз коела.

Чәчләремә йолдыз кагылганда,
Ала алмый торам мин тын да.
Җан рәхәте, тәмуг газаплары,
Бу — татлы төш туган йортымда.

## Көзге уй

Талгын гына яфрак ява юлга,
Соңгы тапкыр көлеп, әй көлеп.
Якын алар миңа, әйтерсең лә
Йөрәгемнән төшә өзелеп.

Талгын гына яфрак ява юлга,
Димәк, тагын җәем җәйләнгән.
Ә җәйләрем минем... юк, гомерем
Шул яфраклар белән бәйләнгән.

Талгын гына яфрак ява юлга,
Талгын гына инде хисләрем.
Гомеркәең яфрак булып оча,
Дисәләр дә, китмәс исләрем.

Талгын гына яфрак ява юлга,
Килә бугай серем чишәсе.
...Әйе, беләм, тормыш юлларына
Бер яфрак мин көлеп төшәсе.

* * *

Зәңгәр күкләр йокыларга талган иде,
Аккошлардай йөзеп китте болытлары.
Уйнак җилләр тынып-тынып калган иде,
Очты алар күбәләкләр булып тагы.
Җиде җете нурын сузды кояш кинәт.
Бар дөньяның күзе бездә мәллә инде?
Җиһанымның ал нурларга чумган мәле:
Улым миңа тәүге тапкыр «Әннә» диде.

## Түп

Нәни улым түп куа,
Үзе көрсенеп куя.
Тубы читкә тәгәри,
Туры барса әгәр, ни
Буласын ул чамалый...
Теләгәнчә чабалмый,
Чөнки тубы алдалый,
Качып-качып калгалый.
Улым эзли, мәш килә,
Бер елый да бер көлә.
Ни булыр түп анласа?
Улымны алдамаса!
Адымнарын хупласа!
Их! Тормыш шул түп ласа...

* * *

Кич укылган әкиятләр аз булган:
— Тагын, әни, тагын ниләр язылган?
Мин укыймын: «Борын-борын заманда...»
Калкып чыга яхшысы да, яман да.

Җирләр тетри, күкләр күкри, яшьни дә,
Тып-тын калып тынлый улым, дәшми дә.
Мин укыймын: «Борын-борын заманда...»
Мажаралар арта гына һаман да.

Әкият, син сабыемны сыендыр,
Яманлыкны җинүләре кыендыр.
Мин укыймын: «Борын-борын заманда...»
Яшәү шулай дәвам итә һаман да.

## Уен

Уенчык пистолетлары
Уенсыз иде әле.
Уйнап кына атып, улым
Уема тиде әле.

Телевизор буе да юк
Мәскәүләр белән ара.
Җан кыялар, кан коялар —
Мәскәүдә сугыш бара.

— Мин дә атам, син егыл, — ди, —
Абыйлар, — ди, — егылды.
Нигә өйрәтәсең, дөнья?
Күземә яшь тыгылды.

Нинди генә сүзләр табыйм,
Әйтсәм дә, тыңламый шул.
И сабый, сугышның уен
Түгелен аңламый шул.

## Сагыну

Җаннарыма ап-ак биләүсәдән
Бер гомерлек бәхет таралады.
Улым минем татлы төшләр күрә,
Күңелкәе анның далададыр.

Нәни улым тәмле төшләр күрә,
Әнкәсенең сизми ут янганын.
Сагынуларга уралдым да менә,
Көтеп торам аның уянганын.

## Язы кар

Көләч күзле бөреләрнең бүген
Хыяллары өшеп корыр кебек.
Һәм салкын кар шулай гомер буе
Буран-буран явып торыр кебек.

Көтмәгәндә бик өшедем мин дә,
Язның соңгы кары яуган көндә.
Талгын сулар уйный сукмагымда —
Эремәслек әрнүләр юк кемдә?

Язның үзәгендә карлар ява,
Аклык аша бөре үрелә күккә.
Ә иртәгә онытылыр бар да,
Кайнар кояш төшәр гөрләвеккә...

## Әйтерсең лә

Уйлар төшсә башка, качып булмый,
Адаштырып булмый урманда.
Уйлар төшсә башка, юллар дәшә:
— Мамык шәлләреңә уран да,
Әйдә, сеңел, офыклар тик алда,
Күкләр күтәрешер, болытлар.
Уйлар төшсә башка, очып китәм,
Кайбер чакта җилләр булыплар.

Бүген миңа хыял канат куйды,
Эзләп таптым җәйге болыным.
Бер башымда кырык уем уйный,
Әйтерсең лә кырык толымым.

## Ятимнәр кышы

Кар да жылы! Быелгы кыш
Ятимнәр кышымы соң?
Табигатьнең ана булып
Назлавы шушымы соң?

Ятимнәр йорты янында
Таулар айга тияр күк.
Юмарт кышка бирәр сабый
Кинәт: «Әни!» — дияр күк.

## Хыял бизим

Хыялымны бизим елтыр-елтыр,
Яңа елның чыршысыдай итеп.
Кемдер аны күреп алыр сыман,
Карап торыр сыман исе китеп.

Хыялымны бизим. Җырларымны
Элеп куям янар шарлар итеп...
Ни кылсаң да, кышлар кышка охшар,
Салкыннары узар бер көн өтеп...

Хыялымны бизим. Кешеләрне
Жылытсын, дип, кояш, көлмәгәндә.
Бәйрәм үтәр, беләм, ә мин бизим.
Бәйрәм әле миңа килмәгән лә...

## Уйлы җил

Җилнең дә төрлесе була шул:
Ачысы, салкыны, карлысы.
Җилнең дә серлесе була шул:
Талгыны, назлысы, баллысы.

Гомернең төрлесе була шул:
Ачысы, салкыны, төссезе.
Гомернең серлесе була шул:
Көннәрдәй яктысы, керсезе.

Язмышка мин каршы баралмам,
Буранда кисәм дә зур толып.
И Ходай, яз мина, һичьюгы,
Исәргә ак уйлы җил булып...

## Еллар – еланнар

— Әтиегез җиңү алып кайтыр,
Тиздән кайтыр менә, оланнар, —
Дип йокларга ятса, төшкә керер
Уятканнар зәһәр еланнар.

Ул бабамның төсен хәтерләми,
Әйткән сүзләрен дә оныткан.
Гомер буе үзе аны сөйли,
Нидер көтә без биш оныктан.

Күзләрен дә, йөзләрен дә кат-кат
Хәтереннән еллар юганнар.
Тузып бетеп, утта янган күптән
Ир җылысын саклар юрганнар.

Тол калган да яшьли, хәзер инде
Яше житеп килә сиксәнгә.
Ире чыгып киткән көннән башлап,
Сугыш дигән сүздән сискәнә.

Ул сугышлы еллар әбиемнең
Алма-яшьлеккәен урлаган.
Сабыйларын бикләп калдырган да
Көн-төн урган колхоз урагын.

Үтәр, дигән, бер көн житәр, дигән,
Сабыр була белгән, сынмаган.
Ә язмышы аны урак тешле
Кайгылары белән сынаган.

Бабам төсен инде хәтерләми,
Эзләрен дә язлар юганнар.
— Үткәннәре үткән, инде хәзер
Сезнең өчен яшим, оланнар.

И, Ходайга шөкер, заманалар
Уракларны ерак жыйганнар, —
Ди әбием. — Агулары — дару,
Һәрбер чорда еллар — еланнар...

## Нигез

Ул да кайтыр бер көн нигезенә,
Иярмәсләр ерак калган еллар.
Туган нигезкәем, диеп елар,
Жаным игезкәе, диеп елар.
Кадакланган тәрәзәгә карап,
Гомеркәем кебек, диеп елар.
Чирәменә сузылып ятар да ул,
Яңа туган сабый булып сулар.

Кадакланган тәрәз капкачларын
Сулкылдатып кубарасы килер.
Читтә аны юллар көтеп торыр,
Читтә башка... Башка кояш көлер.
Сиреньнәрдән яшьлек исе аңкыр,
Бу бердәнбер нигез, изге менә!
Елый-елый, кат-кат борылып карар
Үз-үзенә кайткан мизгеленә.

## Их, нәратлар!

Наратларга мода кирәк түгел,
Гел бер күлмәк гомер буена.
Хыялларга ияреплэр киту
Төшләренә керми, уена.

Мин беркатлы: алсу рәшә — хыял
Төшләремә кереп алдаган.
Тәпиләрем җирдән аерылган
Көнем хәтта истә калмаган.

Мин адашкан шәһәр урамнары
Мода белән генә киенгән.
Җиде ятлар арасында гүя
Бәхетенә бар да тиенгән.

Их, наратлар! Сезгә туган җирдә
Үрелүе җиңел күкләргә.
Горур һәм төз яшәп булмый читтә,
Авыр бөкре чыкты күпләргә.

Иңегезгә башым салыр идем,
Их, наратлар, бәхет аздандыр.
Буш хыялга алданмагач, сезгә
Урман булып яшәү язгандыр.

## Көз һәм малай

Яфраклар уйный һавада,
Көн артыннан ямь арта.
Көзләрне күзәтә малай,
Борынын тарта-тарта.

Борын тарта-тарта, әнә
Якты җыя үзенә.
Көз елмаеп карап тора
Шук малайның күзенә.

— Әй, егет, — диде көз. Борыны
Тигәч җиңе очына.
Кулъяулыгыдай бер яфрак
Төшеп кунды учына...

* * *

Син дөньяны төзәтергә телисеңдер,
Гөлләр төсен үзгәртергә телисеңдер.
Кычытканнан кашкарыйлар калкыр,
дигән
Көннәренә өмет белән түлисеңдер.

Үзгәртергә теләү әйбәт яхшы якка,
Яхшылыкка үзгәрергә теләү әйбәт.
Ә мин яшим кычытканнар арасында,
Аксыл әрем ымсындыра җанны әйдәп.

Каз тәпие басып алган сукмагымны,
Эт эчәге аягыма уралмакчы.
Минем бакчам, бар биләмәм —
утлы утрау,

Яшел монга чумган минем урам,
бакчы!

Менә шуңа үзем генә үзгәрәм шул,
Менә шуңа үзем генә төзәләм шул.
Мин көткәнчә булмавына
бу җиһанның,
Гомерләрем буйларына түзәләм шул.

* * *

Берәр халык үзе үзгәрмәсә,
Аллаһ аларны үзгәртмәс.

*Рәгыд (Күкрәү) сүрәсе,*
*11 нче аять*

Терәүләре ауганны да
Сизмәгәндер өй хуҗасы.
Авыл буйлап җилләр бии:
— Тагын нәрсә кубарасы?

Юк, бу хуҗа үкенгәндер:
Ниятләрең алтын булса,
Нигезеңне салкыннардан
Саклап торыр халкың булса,

Менә тормыш! Менә язмыш!
Бердәмлектә булган көч, дип,
Үзебезне барлыйк әле,
Бергәләшеп иртә-кич, дип.

Эндәшәсе килер анын,
Соң икәнен белә торып.
Әмма җилләр көләр генә,
Чөнки җилләр кигән толып...

Энже-энже кар бөртеген
Шушы халык итәр чәчәк,
Җилләр үткәч, ул барыбер
Тераүләрен күтәрәчәк!

Күтәрәчәк тераүләрен,
Күтәрәчәк шушы халык.
Бу нигезгә яңа йортлар
Корачак ул, булса Алып.

Гыйбрәт ала белербезме,
Бәлаләргә тарып кына?
Үзен-үзе югалтканны
Хәтерләмәс тарих кына.

## Юл башы

Безнең якта берәүләргә
«И юллы бала» диләр.
Берни дә таләп итмиләр,
Көтмиләр әллә ниләр.

Озатып кала әнкәйләр
Авыл башына кадәр.
Күршеләр куана хәтта,
Юл табып килсә хәбәр.

Авыл башында — юл башы.
Галәм гиздерер телләр.
Чит-ят җирләрдә йөрелер,
Күрелер байтак илләр.

Шатланып каршылар авыл,
Кайтыр юл тапса улың.
«Юлсыз» дияр авылдашлар,
Югалып калса юлың.

* * *

Урамыма көзләр керттмим, диеп,
Әкиятләргә килә күчәсем.
Бөреләрнең күзләренә карап,
Каен суын шашып эчәсем.

Өрәңгеләр, букет-букет итеп,
Яфрак сибә сукмак буена.
Юк, әле бу минһа түгел... Түгел!
Кемнәрнеңдер алтын туена.

* * *

Туган яктан ерак киткән саен,
Кыенлаша бара яшәвем.
Атлар саклаган юк болыннарда,
Күргәнем юк яшен яшьнәвен.

Туган яктан ерак киткән саен,
Бөтен юллар никтер чит итә.
Әйтерсең мин канатларым сынган
Бер кош инде тимер читлектә.

Нечкәлеген тоеп сөйләшерлек
Туган телем калган авылда.
Монда тел дә башка. Авыл кадәр
Кирәк түгел хәтта акыл да.

Бер өйрәнгәч, көн итәргә була,
Яшәп була инде ничек тә.
Иртә таңда бүген уяндым күк
Талчыбыктан үргән бишектә.

Ул болыннар төштә эзләп тапты,
Ул яшеннәр тулды языма.
Туган яктан ерак киткән саен,
Якынаям туган ягыма.

Яшел болын төштә эзләп тапты,
Тыңлап ятам яшен яшьнәвен.
Күбәләктәй очып йөрим бүген,
Җиңеләйде кинәт яшәвем.

## Яшим!

Көнем — серле, кайгым — дымлы,
Шатлыгым ялкын минем.
Ишелеп төннәр килсә дә,
Күтәрә ике иңем.

Су — апамдыр, Ут — сеңелем,
Күк — дустым, Ай — сердәшем,
Кояш — әнкәм, Җиһан — әткәм,
Алар барда мин яшим.

Җиргә берегеп туганмын,
Юлларда шуңа үзем.
Җаным — суда, йөрәк — утта,
Күкләрдә ике күзем.

Утларга төшсәм дә үз мин,
Суларда түгел ятим.
Туганнарым, әткәм-әнкәм...
Алар барда мин яшим.

* * *

Йолдыз мин, дип хис итәдер
Үзен ул анда.
Талантсыз җырчы сәхнәдә,
Авырлык — залда.

Талантсыз кеше — тәхеттә,
Кем бите пешә?
Бар авырлык ил өстенә,
Халыкка төшә.

* * *

Кешеләргә рәнҗемәскә иде,
Күзәнәгең саен әрнү тулса.
Күңел гөлкәйләрең кинәт сулса,
Кояш көткән мәлдә тик ай туса.

Кешеләргә рәнҗемәскә иде,
Моңланырга моңың җитмәгәндә.
Кышның салкыннары үтмәгәнгә,
Актарылып бозлар китмәгәнгә.

Кешеләргә рәнҗемәскә иде,
Кызгана, дип, кояш нурын, төсен...
Ак һәм кара буталганда кичен,
Яшәү шулай дәвам иткән өчен.

Кешеләргә рәнҗемәскә иде...

# Кыйбла

Кунак әбекәем кыйбла эзли:
— Кояш, балам, шуннан чыгадыр?
Кыйбласызлык, беләм, тау кадәрле
Хәсрәт булып бәреп егадыр.

Әбекәем намаз укымакчы,
Һәр намазы аңа мәртәбә.
Күңеленнән көнгә нәкъ биш тапкыр
Барып кайта шулай Мәккәгә.

Әбекәем миндә кунак чакта
Чишеләчәк барча төен дә.
«Бисмилла» дип бусагамнан үтте,
Кыйбла эзләп тапты өемдә.

Нигеземә, әйе, кыйбла кирәк,
Ил-йортыма кирәк кыйбла.
Нәсел жебен ялгар жай тапмыйча,
Акъәбиләр китсә, соң була...

Әйе, миңа бүген кыйбла кирәк,
Күрсәт, әби, шушы тарафны!
Намазлыкта фәрештәдәй ак жан —
Гомер бирче берүк, Ярабби!

Сокланыплар торам. Аңа охшап,
Бераз үжәт мин дә, тырыш та.
Үтта пешә, суга төшә-төшә,
Кыйбла эзлим ләса тормышта.

* * *

Җир читенә китсәм — ерак булыр,
Дошманнардан булыр тынасы,
Дип ялгыштым. Һәр почмагы — үзәк,
Түгәрәк лә икән дөньясы!

Җир читенә китсәм, мөмкиндер, шәт,
Гайбәтләрсез бер төн кунасы...
Танышларны җилләр сипкәнмени —
Ах, тар икән ләса дөньясы!

Җир читенә китсәм, михнәт күрмәм,
Дигән идем, ниләр кыласы?
Әйләнә дә, аһ, бер баса икән,
Аһ, куласа икән дөньясы!

* * *

Минем бәхетле халәтем:
Алкадай елтыр иртәм.
Бакчамдагы җимешләрдә
Ожмахтан ингән бер тәм.

Минем бәхетле халәтем:
Зәңгәр күлмәкле күгем.
Ак бөркәнчекле болытлар
Гүя яшь килен бүген.

Минем бәхетле халәтем:
Чишмәләр, агымсулар.
Искән җилем, баскан җирем —
Шигырем менә шулар.

## Бетергеч

Бетерәм, диеп туган ул,
Яшәгән, бетерәм, дип.
Замана ялганын, кат-кат
Ялап, ялт иттерәм, дип.

Бар да фани! Ни үзгәргән?
Ах, көннәр үткән ләса.
Сизми дә калган бетергеч,
Ашалып бетkән ләса!

* * *

Без юк җирдә тормыш рәхәт инде,
Без юк җирдә башка кояштыр.
Мин аркама биштәремне астым,
Әйдә, яңгыр, койсаң коя тор!

Без юк җирдә көннәр якты инде,
Төннәр айсыз булмый торгандыр.
Без юк җирдә ак каеннар саен
Сандугачлар оя коргандыр.

Без юк җирдә яшәү оҗмахтыр ул,
Һәр тотынган эшең кулайдыр.
Без бар җирдә безгә генә кыен,
Һәм тормышка рәхәт... шулайдыр.

## Гүзәл төн

Йолдызлар бер чибәркәйнең
Бит очы миңнәредәй.
Күпереп тора болытлар
Яшь килен мендәредәй.

Әллә ничек якты бу төн,
Әллә ничек караңгы.
Әллә ничек кузгатмакчы
Минем яшьлек ярамны.

Йолдызлар бер чибәркәйнең
Бит очы миңнәредәй.
Ни сөйлидер ай белән җил
Миңа үз тиңнәредәй?

Кайттыңмы, төн! И гүзәл төн,
Үткәнем, хисем булып.
Тузгый-тузгый агып китте
Ак мендәрдәй ак болыт.

## Үтелгән

Үтелгән...
Тормыштан нәрсәдер көтелгән.
Нык үргән толымнар сүтелгән.
Үтелгән...
Офыкка кем барып җитәлгән?
Үзеннән еракка китәлгән.
Үтелгән...
Җанымда яктылык — көтелгән,
Хәтерем йомгагы сүтелгән...

* * *

Тешләр тешкә тими иде,
Бетмәс боз җанда күрәп.
Җылы китерделәр миңа
Кешеләр йөрәк-йөрәк.

Шырпыдай кабынды сүзләр,
Җөмләләр учак булды.
Үлеп барганда терелдем,
Бу ялкын бик чак булды.

Учаклар уй уйлар өчен,
Ялгызым калган чакта.
Ни диеп сөйләрләр инде
Чит-ятлар минем хакта?

Шундый җылы икән киче,
Шундый җылы җил исә.
Тешем тешкә тими иде,
Туңган идем югыйсә.

Рәхмәт, олы күңеллеләр,
Һәм күңеле кечеләр!
Йөрәк-йөрәк җылы илтәм
Мин дә сезгә, кешеләр.

## Кояш әкиятләре

Кояш ашыга кая?
Кичке якта күләгәләр
Озая да озая.

Адымлап саный-саный,
(Үз шәүләсе тугры сәгать),
Вакыт белергә ярый.

Кояш ингән кай ара?
Чыбыркысы гомер кебек
Таушала да кыскара.

Һич әйтмәс: гомер зая,
Күләгәләр көн дә шулай
Кыскара да озая.

Күләгәләр шул чая,
Аңа дигән җәйне тагын
Урлап качканнар кая?

## Бәхетне табып буламы?

Бәхетне табып буламы?
Бәхетне танып буламы?
Утында янып буламы?
Кем белгән.
Хәсрәт үзе киләдерме,
Хәсрәт ачы көләдерме,
Йозак ватып керәдерме,
Кем белгән?
Күңелләр, һай, сизгер икән.
Хәсрәтләре өзәр икән,
Бәхет бары мизгел икән,
Шулайдыр.

# Әбиләр чуагы

Кош каурыйлары коелды,
Болытка тиеп-тиеп.
Йөгереп чыкты кыз бала,
Җәйге күлмәген киеп.

Күтәреп куйды әбиләр
Пәлтәләре якасын.
Тып-тын очты пәрәвезләр,
И назлы җил, сак ла син!

Шулкадәр дә якты кояш,
Шулкадәр иркен һава.
Йөгереп чыкты кыз бала,
Яфраклар ява... Ява.

Йөгереп үтте кыз бала
Яздагыча күзләргә,
Күлмәгенең зәңгәрлеге
Йогып калды күзләргә.

И көлеп тора кояшы,
И чынлап тора һава!
Йөгереп китте кыз бала,
Яфраклар ява... Ява...

Яшь кыз булып елмайды көз,
Елмайды серле итеп.
Бераз ихлас, бераз моңсу,
Бераз мәкерле итеп...

# Яшәү

Ташны ярып, яшь үсенте чыккан,
Үзе күрергә дип үз көнен.
Кырык якта кырылып эше арта,
Дөнья, әнә, мәңге яшь килен.

Карт көтүче төссез эшләпәсен
Кояш чыгышыннан яшергән.
Ә кояшның — төсе уңасы юк,
Башмак илтә язга яшелдән.

Каерылган каен кайрылары,
Тузларына кадәр тузганнар.
Чәчләренә бөре-бантлар тагып,
Апрельләрдән кат-кат узганнар.

Бакырланып толымнары унса,
Авыр булмас көзгә сүтүе.
...Бер яшь килен сарык куып килә,
Каты йоклап, калган көтүе.

Алсу таңы киткән көтүченең
Чыбыркысын иш, дип иярен.
Кайчак мин дә иртәм эзләп чыгам,
Төнге сагышларга сөялеп.

Башлап ачкан олы капкаларым,
Ал таңнарым өчен куанам.
Минем дә бит килен чагым җирдә,
Үтә серле яшәү — каенанам.

Яшь үсенте ташны ярып чыккан,
Үзе күрергә дип үз көнен.
...Без кояшны каршылыйбыз икәү,
Дөнья һәм мин — ике яшь килен.

* * *

Ышанасың кайчагында,
Бусы — Хозыр Ильястыр, дип.
Бөреләрне яфрак итеп
Шаулатырлык зур яздыр, дип.

Ышанасың кешеләргә,
Бусы, диеп, халык улы.
Бусы, диеп, тыңлый белер,
Аңлый белер — итмәс колы.

Ышанасың кешеләргә,
Үзен генә уйламас, дип.
Милләт кадәр милләт белән
Яшен булып уйнамас, дип.

Бер һаваны сулар, дисең,
Бусагаңа басу белән.
...Ышанычы итеп, халык
Юлларына җәя келәм.

Хозыр Ильяс, диеп, бар да
Күз нурларын кат-кат түкте.
Ул өметләр күзге көндә
Яфрак булып очты күпме...

Бер өзелгәч, агачына
Нишләтсәң дә булмый элеп.
Ярый әле, яңа язда
Туа һәрчак яңа өмет...

# Туганым, дигәндә

Чаллы халык театры режиссеры И. Хаҗиның «Өзелгән өмет» спектаклен карагач

Сез йолып алмакчы
Халкымны утлардан.
Ә милләт ишетми,
Ә милләт йоклаган.
Мәңгелек югалту
Юлларын таптаган.
Арыган, талчыккан,
Үз көнен таптаган.
Бу халык сезнеке,
Сез — аның бер улы.
Ут, суга төшәргә
Әзерсез берьюлы.
Сез лә ул сәхнәдән
Җаннарны жылыткан.
Ә халык йокыда,
Сүз тәмен оныткан.
Туганым, дигәндә,
Ачылыр бу күзләр.
Туганым, дияргә
Әзмени гаҗизләр?!
Уяныр бу сүздән
Уйларга калып ул.
Өндә дә яшисе
Бар ласа! Халык ул!

# Вәгъдә

Алсу гөлләр белән килә
Көн дә җәйге иртәләр.
...Бәйрәмнәрдә безгә кайчак
Сүз дә бүләк итәләр.

Телевизор, машиналар
Сүздә бүләк итәләр.
Ә вакытлар, җилләр кебек,
Үтәләр дә китәләр.

Үтә патшалар, хакимнәр,
Чорлар аша җил кебек.
Ә вәгъдәләр вакыт буйлап
Йөри аннан җилпенеп.

Алтын таулар, көмеш таңнар
Сүздә бүләк итәләр.
Буш сүзләр күк, чорлар бушка
Үтәләр дә китәләр...

# Яңа ел чыршысы

Чыршының түрләрдә
Бизәлде гүзәле.
Ул җем-җем утларга
Иярми күз әле.

Теләнгән теләкләр
Тау булып өелде.
Бер кояш астында
Мең яшик, диелде.

Ә чыршы, ябылгач
Ишекләр келәсе,
Бик килде беләсе:
Ник ана үләсе?

# Карт явуз

*Берәүгә*

Бөкресен җилтерәтеп атлар,
Көн башыннан көтәр зур эшләр.
Сәламе шул: чүт елмаеп узар,
Аңа бар да сәер дәрвишләр.

Бүген аны барча татар мактар,
Урысларның хуплар һәммәсе.
Бүген әле тагын бик күпләрнең
Комга терәләчәк көймәсе...

Бүген әле тормыш табынында
Татар белән татар чәкешер.
Тостлар оештырыр алар өчен,
Тик бер яхшы булып ул дәшер.

Хәйлә җинүләрен бәйрәм итәр,
Бер ул гына тик үз иркендә!
Бетховенны, Бахны аңлап тыңлар
Барсы белән бер үк төркемдә.

Үз көенә биер һәм биетер,
Кирәге юк дәүләт ялының!
Аның кадәр беркем серен белмәс
Һәм ләззәтен дөнья малының.

Ул барында, акта кара булып,
Ярылып ятар кемнең кемлеге.
Аңа карап, бик буласы килер
Берәүләрнең дөнья кендеге...

Н

## Юлчы

Бураннарда адашкансың бугай,
Кашларыңа кадәр кар сарган.
Еракларда киләсеңдер, юлчы,
Кош эзе дә төшмәс юллардан.

Шунда тудым, шунда үстем менә,
Килмешәк тә түгел, качак та.
Мин дә шулай юллар эзләп чыгам,
Адашыплар китәм кайчакта.

Утлар күрсәм, кояш сыман була,
Сукмак күрсәм, йөрәк жылына.
...Асфальт җәяләр дә таш түшиләр
Кемнәрнеңдер узар юлына.

Әйе, миңа юлчы булу җитә,
Җәяүле ак буран ияргән.
Еракларда киләсеңдер, юлчы,
Тормыш дигән затлы иярдән
Төшеп калдың мәллә? Нигә болай
Кәефең юк, хәлең, сүзләрең?
Мин дә барам менә. Барам! Чөнки
Офыкларны күрә күзләрем...

## Бишле

Арыдым, талчыктым бүген,
Эзләрдән чыктым бүген.
Йөз кат, үземне аңламый,
Йөземне чыттым бүген.

Хәлсезләндем, бөлдем бүген,
Тереледем, үлдем бүген.

Таллай сыгылдырыр жилнең
Барлыгын белдем бүген.

Көчкә йортым таптым бүген,
Капкамны яптым бүген.
— Әнием, бишле алдым! — дип
Әйтте дә чапты бүген.

Минем улым. Алтынкаем,
Таралды бөтен кайгым.
Ак бәхетле һәм көчлемен,
Патшалар кебек баймын.

Гөлжимештәй көн генәсе —
Чәчкәсе дә энәсе...
Улым алган «бишле» — бүген
Яшәвемнең мәгънәсе.

* * *

Кыз бала учлый да суларга ком ташлый,
Дулкыннар сикерә-сикерә ярларга
ком ташый.
— Ах, ташам, — ди дингез, — арынйык
бу комнан!
— Әнкәйнең йөзләре саргаер... —
Дулкыннар куркынган.
Аларның әнкәсен елаткан мин идем.
Ә хәзер әйтерсең хәтергә тау кадәр
ком өйдем.
Тик суга сикерде жанымның аккошы.
Мин — ярда. Сары ком —
дингезнең рәнжүле сагышы.
Сарылды аякка, хәтерне терелтеп,
Булмый шул суларда сап-сары
сагышны эретеп...

# Җепләр эрлим

Гыйшык тотып җеп эрләсәң,
Җебең нечкә була ул.

*Татар халык җырыннан*

Кылдан нечкә җепләр эрләр чагым,
Әмма заман үткен кылычтан.
Вакытымны кисеп-кисеп ала,
Кисеп-кисеп бирә бер очтан.

Очын очка ялгап, көнем үтә,
Вакыт кыска шундый, шундый тар.
Хәзер киләм, диеп, вәгъдә биргән
Кырык якта кырык эшем бар.

Юл чатында кырык дустым көтә,
Сөйгән ярым ярыла кырыкка.
Заманымның әрсезлеге әллә
Күченмәкче минем холыкка?

Вакытымны кисеп-кисеп ала,
Заман уяу, заман шук, тере.
...Очын очка төйнәп, көнем үтә,
Шул төеннәр — яшәү кадере.

* * *

Күпләрне үзгәртә акча,
Җәмгыятьне, илләрне.
Чирләтә, ди, дәвалый, ди,
Турайта, ди, билләрне.

Мәхәббәткә хуҗа, ди ул,
Сөймәгәнне сөйдерә.

Борыннарны айга кадәр,
Айдан узып чөйдерә.

Хансарайлар салдыра, ди,
Бил бөктерeп коллардан.
Акча хужа булган җирдә
Гөл түгелә куллардан.

Күпләрне үзгәртә акча,
Заманнарны, чүлләрне.
Кыяларны, хыялларны,
Күңелләрне, телләрне.

Шагыйрьне берни үзгәртми,
Җәмгыять тә, илләр дә.
...Хәер, минем күргәнем юк
Акчалы шагыйрьләр дә.

## Зиратта

Карап торам зират капкасыннан,
Җаным елый сулыгып-сулыгып менә.
Мин әткәмә килдем, бабаема,
Әбиемә килдем әле генә.

Йөз ел шунда басып торам сыман,
Күз яшьләрем карашымны кисә.
Ә җил исә... Тынармын күк кинәт,
Бу синең дә газиз йортың, дисә.

Мең ел шунда басып торам сыман,
Тораташтай хәтер катып калган.
Әтием дә исән! Әбием дә!
Бу зиратлар ялган. Ялган! Ялган!

Йөгерәсем киләкире таба,
Әбиемә, мине күтәреп алган.
Үзебезнең капка төбенәчә
Йә юлларга, әткәм озата барган...

Күз яшьләрем инде бишташ сыман,
Яфрак куа җилләр минем алдан.
Кайнар Хәтер көтәр капка төптә:
— Гомер яна... Утлар булмый ялган.

Кабер өсләренә ак каенның
Яфраклары оча кибеп-кибеп.
Сулыгып-сулыгып җаным өзгәләнә,
Мең ел шунда басып торам кебек...

## Автобуста

Ярый сез мине белмисез,
Ярый мин белмим сезне.
— Әйдә, алдагы агайны
Бергәләп этәбезме?!

Юлга баскан, безгә менә
Төшәргә кирәк хәзер...
— Кымшанмый да яшидер ул
Шулай әзергә-бәзер.

...Ах, этмәгез берүк мине,
Төртеп төшерәсез бит.
Бер егылгач, тору авыр,
Авыр, төшенәсез бит.

Оча пәлтә төймәләре,
Кыза автобус эче.
Кем көчсезлеге сынала,
Кемнендер шунда көче.

Этәсем килми һичкемне,
Беркемгә юк ла үчем.
Соң туктылышка житкәнче
Көчсезлегемдә көчем.

## Хыял

Мин дә әби булырмын бер,
Чәчләрем дә ак булыр.
Аклыгыннан нарасый нур
Ургылыр да ургылыр.

Мин дә әби булырмын бер,
Бик ошармын үземә.
Кара күзле оныгымны
Утыртырмын теземә.

Санныйсым да килмәс шунда
Елларымны китетеп.
Онык өчен өйрәнермен
Әкиятләр күп итеп.

Оекбашлар да бәйләрмен,
Йомгакны түрдә сүтеп.
...Түрләрдә дә тоймаганмын
Үземне түрә итеп.

Түрәлекләр үтә. Борып
Булмый вакыт телләрен.
Оныгыма да үз түрең
Булсын, диеп теләрмен.

Оныгым яшәгән илгә
Ихлас дога кылырмын.
Ә беркөнне ил түрендә
Мин бер әби булырмын.
Гади әби булырмын...

## Тын иртәдә

Бер караштa меңәр хикмәт,
Күп мәгънә бар әздә дә.
Ромашкалар пышылдаша,
Алар әле сәҗдәдә.

Алар өчен иртәләр тын,
Җил сулыш алмый тора.
Син дә намаздадыр, әни,
Хәерле көннәр юра!

Миңа, үзеңә, дөньяга
Җан тынычлыгы сора.
Изге таңда изге җил дә
Суларга кыймый тора.

Әле дә юлдамын, әни,
Ерак, озын сәфәрдә.
Кыскасы — аз, уравы — күп
Мин яшәгән шәһәрдә.

Мең догалар кирәк, әни,
Юлларыма чәчмәгә.
Сагынуым чыктай тамды,
Иелдем дә чәчкәгә...

* * *

Мин шигырьдән киткән идем инде,
Ерак идем шигъри хисләрдән.
Мәңге кайтмаска дип, капкаларын
Япкан идем инде кичләрдән.

Иртә таңнан жилләр эчә-эчә
Иреннәрем көйгән мәлләрдә
Мин борылып кайтмам, дигән идем
Шигырьдәге иләс хәлләргә.

Мең юаткан идем инде жанны,
Шигырьсез дә яшәп була, дип.
Шигырьсез дә кояш нурын, әнә,
Әсир итеп бөре тула, дип.

...Күр, тузганак очты күз алдымда,
Ниләр уйлый микән тамыры?
Бәлки, аның ап-ак сүзләредер,
Тузганакның шулдыр таң жыры.

...Бу жил егылып башын бәрер инде,
Кан укмашыр инде бәгырьгә.
Мин жиһанны житәкләпләр шулай
Кайтып барам икән шигырьгә.

Мин сизми дә кайтып барам икән...

## Яңа шәһәрдә

Шәжәрәсез кешеләр юк,
Белмәгәннәр житәрлек.
Тарихсыз шәһәрләр була,
Гүзәл, дип ис китәрлек.

Сөембикә сулкылдавы
Ишетелми ташлардан.
Кол Шәрифләрнең исеме
Хәтерләрдән ташланган.

Меңәр еллык манаралар
Карап тормый күзләргә,
Иман сорап.
Кемдер булә
Ятларга һәм үзләргә.

Дөньяга ят, шәһәргә ят,
Шәһәре ят купләргә.
Шәҗәрәң, тарихың белән
Ашып булмый күкләргә.

Меңьеллыклар аша балкып
Тәрәзәләр карамый.
Бар да үзгә. Этләре дә
Уздырмас күк таламый...

Этләре дә шәҗәрәле,
Белми генә үзләре.
Каршы килгән һәр сылуда
Сөембикә йөзләре.

Сөембикә чалымнары,
Сөембикә сыннары!
Монда бар да югалтулы,
Сак-Сокларның сыңары...
...Аһ, тәкъдирнең билгеле ич
Безне мәңге сыңары.

* * *

Өзелде дә төште яшел яфрак.
Бу күзләргә инде ни дисең?!
Шунда гына мин җир исен сиздем,
Шунда гына тойдым җил исен.

Кабынды да сүнде якты йолдыз,
Атылды да янды бер җисем.
Шушы мәлдә мин күкләрне күрдем,
Иркен. Азат. Килде яшисем.

Күлмәгемнән яңгыр исе аңкый,
Чәчләремнән килә җил исе.
Яфрак белән йолдыз арасында
Бер гомерем бар ла җиллисе...

* * *

Кемнәр бүген бриллианттыр
Алтын йөзек кашында?
Бер фикере кирәк түгел
Мең акыллы башның да.

Моң ургый, ургый, агыла,
Күзләрне теләр итеп.
Иркенсең, дөнья! Үземне
Тоям шыр җүләр итеп.

Гармуннар тарткандай тартам
Күңелемнең күреген.
Ярылсаң да, чикләп булмый
Шыр җүләрнең ирегеn.

Канунга көй язам, дисән,
Сугачаклар түбәгә.
Түбәләргә суккан саен,
Сары йортлар күбәя.

Ташлар сары, жыр саргаймый,
Жырлар мәңге кипмәгән.
...Әлегәчә ничек йөрәк
Шагыйрь булып типмәгән?!

## Ялгызлыгым

Ялгышыммы, язмышыммы,
Ялгызлыгым — ачы гамь.
Шунда минем ак бәхетем,
Шунда минем фажигам.

Бары шунда яшәвемнең
Беркем чишәлмәс сере.
Мәхәббәтнең һәм нәфрәтнең
Миндер ул бердәнбере.

Алар мине бу тормышта
Сайлаган юлдаш итеп.
Ялгызлык чикләре буйлап
Йөретер өчен этеп.

Үттеләр-киттеләр, дисәм,
Бәгырьне тетеп-тетеп.
Ялгыз жанга ялгышу ни,
Тормыштан нидер көтеп.

Гомерем дә янар шулай,
Жандашсыз, парсыз, ярсыз.
Өемдә, илемдә түгел,
Ялгызлыгымда ялгыз...

# Яңа ел көткәндә

Йолдыз явар микән, ак карлармы
Яңа елның гүзәл төнендә?
Һәрбер җанның гыйшкы бәйрәм көтә
Гасырларның капка төбендә.

Ялгыз сагыш акка төренгәндә,
Өмет булып карлар коелыр.
Узган еллар якты үткәннәрнең
Ап-ак сере сыйган коедыр.

Чыршыларга янә янар шарлар,
Энҗе муенсалар эләрләр.
Ә чыршылар бер якты төн өчен
Аягүрә көлеп үләрләр...

Мәңгелектә бәйрәм генә һәр чор,
Могҗизасы гүя бу төндә.
Аклыгыннан мәрхәмәтле дөнья
Мәхрүм итмәс бүген этен дә.

Кемнең яшьлегенә сөю, кемнең
Картлыгына яшьлек өстәлер.
Һәммәсе дә түрнең уртасына
Тартып куяр бүген өстәлен...

Яңа елга сәгать суккан мәлдә,
Тәрәзәгә төшәр күзләре.
Былтыргыдан аграк явар карлар,
Шундый тере булыр үзләре!

Былтыргыдан матур булыр дөнья!
Йөрәкләрне сөю пешерер.
Ә чыршылар узып барган елның
Ал шарларын искә төшерер.

Ак бөртекләр жанга тезелер дә
Калыр безнең гомер җебендә.
Имин булсын!
Яңа еллар көтә
Гасырларның капка төбендә.

## Нокта

Бер ноктага төбәлгән бу халык,
Экраннарга заман этәрде.
Думаларга акыл җитәр микән,
Думаларда сүзләр бетәрме?

Чуалалар уйлар, өскә һаман
Кирәк фикер чыкмый өзелә.
Сизелми шул өйдә дәүләт бары,
Телевизор бары сизелә.

Думаларга акыл җитәр микән,
Табылмаслык сүзләр юк та соң.
Бер ноктага төбәлгәннәр күзләр,
Кайда безнең яшәү ноктасы?..

* * *

Адымнары җилләр кебек җиңел,
Ә күзләре көннән яктырак.
Ул кояшка карап бара бүген,
Ә бүген ул калмас аптырап.

«Сөям» дигәненә «мин дә» дияр,
Аннан көләр язны чыңлатып.
Ак болытлар үтәр якты сибеп,
Тузгак чәчкәйләрен чылатып.

Җилләр кебек очып кына житәр
Ул күкләрнең жиде катына.
...Кояш баер. Болыт та ак булмас,
Һәм борылып карар артына.

— Юк, сүнмәскә тиеш иде, — дияр, —
Кояшыма кемнәр кызыга?
...Менә мин дә хәтер тәрәзәмнән
Карап торам шушы кызыйга.

## Сөенче

Яланаяклы малай күк
Йөгереп килдең көздә.
Ах, исән икән бит әле
Сөенче дигән сүз дә.

Сөенәсе микән, белмим,
Көенәсе түгелме?
Ах, сөюем, бер хат булып,
Йөрәгемә түгелмә!

Сөенергә уйлап тору,
Уйлап кына сөену.
Дөньясына ят итмәсме
Бәхетләргә тиену?

Елак микән, жырлак микән,
Белмим нинди микән без?
Үзебездән шундый ерак,
Шундый ерак киткәнбез.

— Сөенче, дөнья! Яңа көн!
Бер сүздән күңел үзгә.
Яланаяклы кызчык күк
Йөгереп кердем көзгә...

* * *

Көтелмәгән бию бии
Ал нурлар мине камап.
Җилле чәчемне тарадым,
Юеш асфальтка карап.

Иннек сөрттем, күзгә иттем
Пыяла ишекләрне:
— Дөнья нинди матур! — дидем,
Яшердем бар шикләрне.

Һәрбер юеш яфрак — көзге.
Көзге булды күзләр дә.
Һәм үземне күрдем синең
Үтә зәңгәр күзләрдә.

Җилле чәчләр, якты караш:
Мин синең күз алдында!
...Көзгеләрем тоныкланган,
Ятлар табып алганга.

Мөгаен, инде аларга
Читләр карашы тулган...
Ятлар йөрер юлга төшеп
Чәчелгән дә ватылган...

Күпме яфрак — челпәрәмә,
Барысы берүземә!
Әллә ничек текәп карыйм
Бүген көзләр күзенә.

# Юлга чыгам

Көяз бөдрәләрен жилгә чөеп
Кайтмый калган иде көтүдән.
Адашкандыр бәрән. Төшләремдә
Тыелалмам эзли китүдән.

Кырда гына тотып алмасыннар,
Урманнарга гына кермәсен.
Канун бозмый читләп кенә үтсен
Бу дөньяның барча төрмәсен.

Намуссыз, дип, оятсыз, дип сүкмим,
Ашап үскән өен оныткан.
Бер хыялы аны көтүеннән
Шактый ерак алып ыргыткан.

Яфрак сыман жифер-жилфер йөрәк,
Киткән йөрәк болай типмидер.
Эзлим, табам. Аякларым яна,
Иреннәрем юкка кипмидер.

Ак бөдрәле нәни бәрәнкәем,
Төштә кат-кат таптым бит инде.
Куеныма сыендырып очтым,
Өйгә алып кайттым бит инде.

Югалтулар авыр, бәрән. Юкса
Миннән тумагансың, и бала!
...Бәрән булсам...
Куеныңа салып кайтыр идең,
Юлга жыенам, әнкәй, кузгалам!

# Кабатланмый

Яшәгән, ди, бер исәр,
Зур эшләр кылган, ди, ул.
Хакимнәргә хезмәткә
Яраксыз булган, ди, ул.

Бар белгәне кәгазь, ди,
Бар байлыгы — каләм, ди.
Ни язганы — дөньяга
Гыйбрәт, ди дә сәлам, ди.

Һәр гыйбрәттә — акыл, ди,
Һәр сәламе — асыл, ди.
Бер сүзенә табигать
Сыйган, ди. Дүрт фасыл, ди!

Халык ятлап алган, ди,
Шаккатып сүз серенә.
Акын итеп исәрне
Утырткан, ди, түренә.

Ул язганнар беркөнне
Күчкән хаким теленә.
И борчылган, ди, халык:
— Шактый исәр күренә!..

Кабатлана дәверләр,
Баһадир, әзмәверләр,
Патшалар һәм хакимнәр.
Кабатланмый шагыйрьләр!

## Гармун тотсам

Гармун тотсам, җаным көя,
Нишләтим бу бармакны!
Көйләре дә, яшен төсле,
Әллә ничә тармаклы.

Әллә ничә тамыры сон
Җаннарыма тоташа.
Зур дөньяга нәни коштай
Карыйм һаман моң аша.

Гармунсыз жансыз кебек мин,
Уйнар идем сыздырып.
Турыгызга оя корган
Сандугачтан уздырып.

Их, гармун моңнары булып,
Күңелләренә тулсам!
Мондый уй уйлар идемме,
Гармунчы булып тусам...

* * *

Юлга төшкән яфрак нинди якты!
Китәсез дәмени, китәсез дә?
Яшьлегемне алып килдегез дә,
Минем җаным китә кебек сездә.

Кайтарыплар булса икән барын,
Агымсуны булса икән борып.
Җилгә каршы барып була да сон,
Язмышларга каршы булмый барып.

Якты яфрак миңа якын бүген,
Җәй эссесе бүген көздә, сүздә.
Бу бер җөмлә яшьлек моны сыйган:
Китәсез дәмени? Китәсез дә...

## Язгы кар

И кар бөртеге, туганым,
Ярсый да ургый ташу.
Икебез дә бер язда без, —
Син дә су шул, мин дә су.

Бер дәрьяда янасы бар,
Бер кояшта пешәсе.
Бер ташуга кушыласы,
Бер упкынга төшәсе.

Агыласы, ургыласы
Һәм ак булып каласы!
Икебез дә бер могҗиза —
Бер табигать баласы.

* * *

Мин белгән берничә йолдыз бар,
Мин күргән күпме гөл исемсез.
Күрдем дә буталдым уйларда,
Кем соң Сез?

Мин баккан йолдызлар ят түгел,
Яктысын күрергә телисез.
Бар сүзләр сөер сер эчендә,
Кем соң Сез?

Елмаеп дәшәсез еракган,
Якыннан. Үз итеп йөрисез.
Җырларым яратып, таратып,
Кем соң Сез?

Бик күпләр күкләргә күз атып,
Танырмы Сезне дә — билгесез.

Кемнәрнең йолдызы, җыр-көе,
Кем соң Сез?

Күпме нур китмәгән күзләрдән,
Күңелдә кипмәгән күпме сүз!
Һәм дөнья ямьләнгән шулардан,
Кем соң Сез?
Яшәү күк билгеле-билгесез...

## Могҗиза

Ак болытлар — ак күбек...
Мин салават күпереннән
Йөгереп үттем кебек.

Исең китеп торасың,
Син безнең һәр якты мәлне
Могҗизага юра соң!

Мизгел яшәүгә риза.
Салават күпере кебек
Булсам якты могҗиза.

## Каз өмәсендә

Чыңлап тора җылы мунча эче,
Ап-ак казлар ята итәктә.
Уйнап-уйнап очкан ак мамыклар
Үпкәләргә кадәр үтмәктә.

Әнкәй юри әйтеп куя шунда:
— Канат сипмисезме юлларга?
Кем очраса, шул яр булыр, диләр,
Бер мөмкинлек — бәхет юрарга...

Шаяртуга алган була кызлар,
Күккә ашкан хыял түбәсе.
Их, чыгасы килә капка төпкә,
Их, юлларга канат сибәсе!

Казлар симез, көзләр, көннәр якты,
Туйлы итәсе иде бу кышны.
Их, тәкъдирне белеп булсын иде,
Язып булсын иде язмышны!

Казлар кебек актыр гомер юлы,
Каз мамыгы кебек җиңелләр.
Кызлар күңеле — беренче кат хыял
Авырлыгын тойган күңелләр.

Их, чыгасы килә капка төпкә,
Их, юлларга канат сибәсе!
Туктап калган яшьлек сыман болыт,
Күккә ашкан ап-ак түбәсе.

Серле итеп әйтеп куя әнкәй:
— Көннәр кыска көздә, кара төн...
Кемнәр йолкыган да кем сипкәндер
Әнкәйләрнең хыял канатын?

...Ул җил бүген янә мунча янда,
Сиздермичә генә ала тын...

* * *

Чикләвек ватарга сау тешләр җитәдер,
Җилләргә очтылар сүзләрем — читтәдер.

Чикләвек булып һич чишенмәм — төшенәм,
Сез мине эзләгез сүзләрем төшеннән.

Мин тоташ сердән шул: табигать сер иткән,
Хатын-кыз иткән дә үзенә бер иткән.

Бар гамем, халәтем сыярлык сүзләргә,
Бүтәнчә ачыла алмамдыр сезләргә.

Нибары бер йөрәк кирәктер — төшенәм,
Сез мине табарсыз сүзләрем төшеннән...

## Алма

Юк, өнемдә түгелсендер,
Татлы бер төштәнсендер.
Бәхет агачыннан җиргә
Өзелеп төшкәнсендер.

Мин дә шул татлы агачта
Алланып тулган чакта,
Җилләр исте зәһәрләнеп,
Каерып төрле якка.

Тәгәрәүләр кыен түгел,
Җиңел дә түгел, белсәң.
Көләсе чакта еласаң,
Елыйсы чакта көлсәң.

Яшәп булмыймыни җирдә,
Тибрәлми дә җилләрдә.
Җаным тулы җөйләр, дисәң,
Санарлар тик җүләргә.

Ләйсән яңгыр битем югач,
Җил киптереп алгач та,
Мин менә ялганмак булып
Йөрим шушы агачка.

Ялганалмам — хакыйкать бер,
Яфраклар оча, оча...
...Үз агачын кемнәр күрсен,
Өзелеп карамыйча?!

## Көзге шигырь

Чегәннәрне урап-урап үтәм,
Урап үтеп булган өчен бугай.
Тагын менә сентябрьгә кердек,
Сары итәк җилпеп йөрер бу ай.

Бик еракнан балкып елмаер да,
Якты язым диеп ышанырмын.
Күрермен дә яшьлегемнең йөзен,
Күпме танышларны мин танырмын.

Яфрак булып очып киткәннәрен,
Ышык эзләп кереп кипкәннәрен.
Көзге җилгә ялгыш ияргәнен,
Йөгерә-йөгерә кышка үткәннәрен...

Һәрберсеннән нидер калган миндә,
Һәр югалту ярсып ташып тора.
Югалтулар әллә алда микән:
Юлда тагын чегән басып тора.

Сентябрьдәй елмаеплар көтә,
Мине алдап, ул көн итмәк шулай.
...Язмышларны урап үтә алмыйм,
Урап үтеп булмаганга бугай.

## Туган җир

Авыл өсте төтен сыман болыт,
Әнкәй мунча яга торгандыр.
Авыл өсте болыт сыман төтен, —
Ах, җаннары яна торгандыр.

Адымнарым болыт сыман җиңел,
Төтен сыман ап-ак уйларым.
Безнең мунча төтене дә хәтта
Беләм күккә ак нур уярын.

Мин кайтам да китәм сагыш төяп,
Кыен килсә, эшем уңса да.
Бу дөньяның барча кере калсын
Авылымда, ап-ак мунчада.

Бу дөньяның барча борчуларын
Төтен итеп җилгә очырган
Әнкәем бар. Шуңа ак болытлар
Туа безнең морҗа очыннан.

Мин аларны таный-таный кайтам,
Мин аларга күптән тотынган.
Кара төтен, бәлки, утыннандыр,
Ак төтеннәр йөрәк утыннан!

Авыл өсте янә ап-ак болыт,
Әнкәм янә мунча ягадыр.
Туган җирсезләрнең күңелләре
Керледер лә, тоташ ярадыр...

* * *

Иренеңә жыерчыклар төшкән,
Чыклар төшкән чакта гөлләргә.
Әллә ничек сәер карыйсың син,
Елмаерга белми, көләргә.

Иренеңә жыерчыклар салып,
Күпме ачы җилләр йотылган.
...Бу тормыштан барсын алдым, дигән,
Оттым, дигән һәркем отылган.

## Йөрәк

Шундый зур йөрәк ул миндә,
Чиксез зур йөрәк инде.
Гүя галәм жылытырга
Бер йөрәк кирәк инде.

Ялкыны кирәк көннәргә,
Яктысы кирәк төнгә.
Сабырлыгы кирәк, дошман
Кулларын салса иңгә.

Көч-дәрте кирәк үземә,
Ак теләге ярыма.
Ах, сызлый да әнчи менә,
Әллә бүген ярыла?

Шундый зур йөрәк ул миндә,
Тынмас һич кенә инде!
И талпына нәни коштай, —
Шундый кечкенә инде...

* * *

Юк, үземне биек итеп күрмим,
Кошлар оча миннән биектә.
Һәм, түбән дә, димим. Әнә бөҗәк
Бөек булмас, күккә чөеп тә.

Мин үземне фәрештә дә, димим,
Ак канатлар бары хыялда.
Ак калулар кая?! Мең төс аша
Мең кат үтеп, мең кат буял да.

Мин җенел дә яшь алганым юк,
Һәм авыр да түгел, түзәрлек.
Күзгә төртсәң, күренмәслек төндә
Шигырь булып калка гүзәллек.

Ямансулыйм мин киләсе чакта,
Елар чакта куям көлеп тә.
Тормыш мине чеметкәләп сөя,
Иң газизе итеп эләктән...

## Күңел

Гомер буйлап тайгак юллар
Сузылыр да сузылыр.
Карашларның көче китәр,
Җыерчыклар сызылыр.

Юл читендә туктап калыр
Шат яшьлегем арыр да.
Тайгак юлларны чылатып
Үтәр шаян яңгыр да.

Мин барыбер туктап калмам,
Мин барыбер атлармын.
Җиген бирмәс бүген язмыш
Җегәрле пар атларын.

Әй юлларым, әй яшьлегем,
Калачаксыз беркөнне.
...Сары яфрак итеп тормыш
Яратмагач бөреңне,
Саргаюлар сере нидә,
Һәм җиргә түгелүнең?
Бер гомердә үтмәс, үтмәс
Яшьлеге күңелемнең.

## Кунак булып кына

Кунак булып кына килгәнбез дә,
Хуҗа булып алмакчыбыз җиргә.
Бүлгәлибез аны, таркатабыз
Йә сатабыз бата-бата тиргә.

Кунак булып кына килгәнбез дә,
Анламыйбыз гомер очарын да.
Әйләндерер идек сыман һаман
Зур дөньяны бармак очларында.

Без кояштан тартып алыр идек
Мәңгелеккә җитәр исәнлекне.
Кунак булып кына килгәнбез дә
Онытканбыз кунак икәнлекне.

* * *

Халкым кебек, моңнары да
Энҗе булып чәчелгән.
Мин аларны җыймак булам
Хәтта җилләр чәченнән.

Хәтта төннең күзләреннән,
Хәтта кояш нурыннан.
Хәтта дәрья төпләреннән,
Энҗе шыткан урыннан.

Көтүче бардырмы, белмим,
Дөньяның мин җүләрен.
Җыеп киләм заман буйлап
Халкымның энҗеләрен.

## Уйламыйча

Уйламыйча әйткән сүзләремнең
Кире алам, барсын кире алам.
Җаннарымны ярып туган түгел,
Алар минем сөмсез үги балам.

Уйламыйча кылган гамәлләрем
Үземә үк урап кире кайтыр.
Дөньям караңгыдан сулармын мин,
Гомерем бушка яну төмен татыр.

Уйламыйча яшәү мөмкин микән,
Сүзләрнең дә иң төксесе булып.
Кире кайтыр бар да. Мин янармын
Бу дөньяның бер үксезе булып.

* * *

Хыялымдай
Тип-тере
Бу — салават
Күпере.
  Зөһрә кызның
  Басмасы.
  Басмасымы?
  Тасмасы
Очып калган
Чәченнән,
Күкләремә
Чәчелгән.
  Җиде нуры —
  Җиде юл.
  Минем өчен
  Микән ул?
Тасма-тасма
Сукмагы.
Юк, сукмаксыз
Һәр ягым.
  Үгисеткән
  Язмышның
  Чайпалдырмыйм
  Ялгышын.
Зөһрә кыздай
Төнемдә
Пар чиләкләр
Иңемдә...

* * *

Мин юллар табалмый йөргән
Хат микән, әллә хәбәр.
Әрнетмәскә иде дөнья
Бер мәлдә шунын кадәр.

Бүген гарьләнмәскә иде,
Үлмәскә иде бүген.
Тормыш, миннән бу кадәрле
Көлмәскә иде бүген.

Итәгемә тамган яшем
Танымый да иясен:
Зур җиһаннын зонтигында
Ләйсән бии диярсең...

* * *

Соң өлгердем. Язлар житкән, дисәм,
Инде күптән жирләр кипкән иде.
Хисләремне салыр ташулары
Ургый-ургый агып киткән иде.

Соң өлгердем. Җәйләр иде жирдә,
Ак әремнәр орлык коя иде.
Моңсыз-жырсыз калган сандугачлар
Баш очымда оя-оя иде.

Соң өлгердем. Көзләремне күрдем
Кошлар китеп барган ак болытта.
Жиргә төшкән сары яфрак гүя
Иярмәкче иде мин булып та.

Соң өлгердем. Кашкарыйлар кебек
Керфегемә ак кар кунгач кына,
Мин кышларның бар аклыгын тойдым,
Бозларына ябышып туңгач кына...

Ни югалттым? Берни югалтмадым.
Яшәгәндә ни югалтып булсын?
...Бүген менә сине төштә күрдем,
Иртә язда. Дөньям — яңа тылсым.

## Балачак

> Бал, дисәң, бер кими,
> Бармак төртсәң, ике кими,
> Кашык сузсаң, гел бетә.
>
> *Халык иҗатыннан*

Канатларым парлы чак,
Унда — әнкәм, сулда — әткәм,
Балачагым — баллы чак.

Балачагым — баллы чак,
Күзләрем дә, күлмәгем дә
Гөлле чак та, аллы чак.

Бал, диюгә, бер кими,
Балдай татлы төшләрен дә
Тормыш җанга бөркеми.

Кашыгымда бал мәллә?
Төшләрдән дә рәхәт миңа
Балачаклы бу мәлдә...

* * *

Гөлле өйгә төс керә,
Кеше зәвыклары төрле,
Кемгәдер яран кадерле,
Кемдер борыч үстерә.

Сыймый дөнья бер учка.
Кеше язмышлары төрле,
Берәүләрнең яран төсле,
Берәүнең тиң борычка.

## Талантлар

Талант булып туган өчен җиргә,
Мең мәртәбә җавап тотасы.
Сиратларны кичеп, ут көенчә
Җиде төсле утны йотасы.

Талант булып туган өчен җиргә,
Сулыш өзәр җилләр табылыр.
Талантлылар кара түгел, түгел,
Бу дөньяның ап-ак табыдыр.

Караларга төшкән ак таптыр ла,
Күнелләргә төшкән кубәләк.
Мең караштан карангылык иңәр,
Сугарга дип үрелер мең әләк.

Ул барыбер ап-ак көе калыр,
Ап-ак булып балкыр аннары.
...Аклык аша карап тора кебек
Талантларның газиз җаннары.

* * *

Тагын кич. Кояш тауларның
Артына төшеп ята.
Кабарып ята ачулар,
Үчләре пешеп ята.

Дошманнарның
безгә дигән
Сүзләре ил өстендә.
Ил авызын тыгар өчен,
Йолдыз житмәс бу төндә.

Тагын кич. Ят дөньяларга
Сыймас ачу, үчләре.
Атылган йолдызлар кебек
Янып бетәр эчләре.

Безнең сүзләр үзебездә,
Һәр сүзнең үз куышы.
Хәтта дошман турында да
Сөйлибез йолдыз кушып,

Бахырларга йолдызлардан
Чир йокканын белсәк тә...
Тешләргә һич уйлаган юк,
Үрелгән юк терсәккә.

Тагын кич. Кояш тауларның
Артына төшеп ята...
Жилләр исә, сулар ага,
Һәм шулай ук таң ата.

* * *

Бер сукмактан йөри җирдә хаклары вә ялганнары,
Патшаларның әйбәт була үткәннәрдә калганнары.

Ир-егетнең данлы була мең игелек кылганнары,
Тик нишлисе, гөлләр янда тибрәләдер кылганнары.

Дошман белән бардыр инде зарлы күрше булганнары,
Әмма халык хәтерендә яши Кеше булганнары.

## Үзенчә

Үзенчә итәсе килә,
Иярмен китәсе килә,
Аһ, шаян җил, елгыр җил!
Әйтерсең бу шул мизгелдә
Мең упкыннан йолыр җил.

Үзенчә агасы килә,
Бер җырлап аласы килә,
Агымсу, агымсуым!
Җырың белән мәңгелектә
Калам, дип, ымсынуың.

Үземчә яшисем килә,
Елый-елый, көлә-көлә,
Ялгыз салам эзне мин.
Агымсуга каршы йөзәм,
Куйдым җилгә йөзне мин.

* * *

Ташлар булып булмас инде,
Таш эзлиләр тирәмдә.
Баш ватардае табылыр
Әле миңа дигәндә.

Кылычлар да кисмиләр, ди,
Газиз башны игәндә.
Җил дә тына, ук та сына
Ташка килеп тигәндә.

Катысын да, салкынын да
Тоймам кебек түбәмдә.
Ташлар белән уклар уйнар
Минем жаннан түбәндә.

* * *

Керфек кагарлык хәлем юк,
Сиратны мең кат кичеп.
Ничек үткәрәсе көнне,
Яшәп бетәсе ничек?

Һәр аткан укны күкрәккә
Медальдәй тага-тага,
Ничек елмаеп барасы
Алсу таңнарга таба?

Күтәрәсе иде башны,
Кара болытлар югач.
...Күкләргә карап барасы
Хатын-кыз булып тугач!

* * *

Шатлыгымны сиңа бирәм, дөнья,
Рәшәләрең биеп алсын бер!
Болытларың тулып ташысыннар,
Давылларга күчеп ярсын бер.

Көләч булып балкы, төннәрең дә
Рәхәт булсын минем шатлыктан.
Кешеләр бар: бер сөенеч күрер
Көннәренә коштай атлыккан.

Шатлыгымны бүл дә өләш, дөнья,
Кояш нурың итеп тарат та.
Очар кошка, искән җилгә өләш,
Һәм калмасын юкә, нарат та.

Кешеләргә карап көлеп торсын
Бер шатлыгым өчен мең иртә.
...Ә үземме, дөнья? Бер куаныч:
Кыйпылчыгың булсам — шул җитә.

## Шигырет

Бәсле керфегемә басып,
Күземә тулган иде.
Сандугач сыман күшеккән
Җаныма кунган иде.

Уйларым очы чуалган,
Ашыгыч иде юлым.
Саз-каләмгә үрелергә
Соңлаган иде кулым.

Җилләр кебек очып үттем
Минутларның арасын.
Югалтканмын, очырганмын,
Инде соң шул, кара, соң!

Көнем тыгыз, юлым урау,
Гамьнәр тулы шыгырым.
Вакыт сыман, бәхет сыман
Очкан киткән шигырем...

## Елыйм, көләм

Елыйсым килә, елыйсым,
Мин көләм тыштан, көләм.
Үләннәндерме, гөлдәнме
Син басып килгән келәм.

Мин ташларга басып йөрим
Һәм йөрим сине көтеп.
Гөлдәй сулган көннәремне
Һәрвакыт синле итеп.

Якты өмет озата мине,
Гөлләре тагы булыр.
Ә юлларның барыбер бер
Кисешкән чагы булыр.

Елыйсым килер шул чакта,
Үтәрмен көлә-көлә.
Көлүем белән җанынны
Парәләп телә-телә.

Кисешкән юл ике якка
Аерачагын белеп,
Сөенермен... Һәм китәрмен
Мин, елый-елый көлеп.

## Ярый әле

Ярый әле диңгез ерак. Гомерем
Алтын балык көтеп үтмәде.
Ярый әле, нәкъ мин теләгәндә,
Битләремнән кояш үпмәде.

Минем көйгә җилләр исмәделәр,
Кошлар очмадылар учымнан.
Ярый әле кышын гөрләвекләр
Йөгермәде аяк очымнан.

Кирәк чакта үзем эзләп таптым,
Сулар эчтем ятып арыктан.
Атлап, йөгереп, йөзеп барганда, мин
Бәхетлерәк алтын балыктан.

* * *

Сүз хакына энә күзләреннән
Сират аша үткәрмәгез мине.
Таптамагыз әле, таптамагыз
Һәм култыклап күтәрмәгез мине.

Минем янда бик йөрмәгез әле,
Күбрәк булыр бәла-казам гына.
Саклана да, яклана да белмим,
Ни уйласам, шуны язам гына.

Ут уйната күктә, кылыч болгый,
Кемнәрнеңдер тынычтыр көр җаны.
Мин таптый да һәм таплый да алмыйм,
Һәм мактый да алмыйм бу дөньяны.

Алма кебек кызыктырган өчен
Бүленмичә калды аздан гына.
Ә мин аны һаман бөтен көе
Сакламакчы булып язам гына.

# Тукталыш

Чайпалып сулар сөенде
Гап-гади теләгемә.
— Коедан тартып алам, ай,
Чум әйдә чиләгемә!

Корыч тавыш, бәллүр чыңнар:
— Әй, чибәркәй, исәнме!
— Исәнмесез! Абау, ялгыш...
Ай эндәшә дисәмме...

Коедай тулы чагым бу,
Коедай айлы чагым.
...Юлларымның кай чатына
Туктала алам тагын?

Битемне суык пешерә,
Бу — кышкы челлә менә.
Су юлыннан кайтып киләм,
Ай салып чиләгемә.

Ай кебек тулган чагым бу,
Ай сыман якты шәлем.
Туп-тулы чиләгемдәге
Су кебек бәллүр мәлем.

Коедай ташкан чагым бу,
Коедай айлы чагым.
Гомернең кайсы чатына
Туктала алам тагын!..

* * *

Бүген минем тәрәзләрем якты,
Көннәр буе кояш уйнады.
Яраннарым, чәчәк ата-ата,
Синең хакта бер уй уйлады.

Көлә-көлә, нурлар йөгереп керде,
Кодрәт тә бар язда, сәләт тә.
Бар дөньяга ачылырга тора:
Тәрәзләрем минем халәттә.

* * *

Мин диңгездән бик еракта яшим,
Һәм сагынам бик еракган торып.
Төшләремдә коштай очалмасам,
Көртләр ярып китәм, карлар ерып.

Мин диңгезгә барам гомер буе,
Кышлар, язлар баса сыман инне.
...Янәшәмдә тоеп сагынам гел,
Син нәкъ шушы диңгез сыман инде.

## Яз буласым килә

Минем дә бер яз буласым килә,
Гөл-чәчәккә килә ураласым,
Таҗым саен нур җыясым килә,
Күзәнәгем саен сут аласым.

Минем дә бер яз буласым килә,
Йөгерәсем килә гөрләвектәй
Сезнең урам буйлап.
Яз ялкынын
Күзләремдә генә дөрләтеп, әй!

Кояш янына энҗе тамчы эләм,
Түбәгездән тып-тып кояр өчен.
Урамда кар ява. Ә барыбер
Гомер буе яз мин хыял өчен.

## Мәхәббәт тудырдым

Хыялым түрендә тергездем мин аны,
Яп-якты мәхәббәт иде бар булганы.
Баһадир гәүдәсен тудырдым сөюдән,
Курыктым үземнең күзләрем тиюдән.
Хыялда яраттым...
Ә көттем тормыштан,
Сөям, дип әйткәнен
тыңларга тырышкан
Мин идем. Тик нишлим?
Азактан аңладым.
Мәхәббәт тудырдым...
Җан өрә алмадым...

## Исемдә, дисең

Исемдә, дисең, исемдә...
Ядәчләшмәдек кебек.
Күлләрдә казлар коена,
Су өсте ап-ак күбек.

Каз гына көттек, дөньяны
Көтү барын белмәдек.
Каз өмәләре үттеләр,
Бер вәгъдә дә бирмәдек.

Кыр казлары төркем-төркем,
Ияргәнбез, киткәнбез.
Ике төркем ике якта,
Табышмабыз бүтән без.

Икебездә ике оя,
Күл өсте канат, күбек.
Исемдә, дисең, исемдә...
Ядәчләшмәдек кебек...

## Сиңа

Бу дөньяда вакыт җитмәс инде
Бер туйганчы сөйләшергә безгә.
Тегесендә, бәлки, башкачадыр,
Гомер дигән төшенчәләр үзгә.

Үзгәрергә туры килер микән,
Белмим, безгә теге дөньяларда?
Көнгә ничә төрле давыл җанда,
Дулыйлар да менә, тыналар да.

Давылларның үзәгенә басып,
Карап тормак булам күзләренә.
Җилләр яфрак сибә эзләренә,
Ашыгасың син дә көзләренә.

Бу дөньяда вакыт җитмәс инде,
Айлар кыска шундый, еллар кыска,
Сүзләр кыска, охшаш язга-кышка,
Һәммәсе дә оча коштай оста.

Дөньяларның кайсысы да ярар,
Рухың белән янәшәмдә булсаң.
Бер мәртәбә үзең өчен яшәп,
Минем өчен җиргә кат-кат тусаң.

* * *

Бәхетемне кыерсыттың бүген,
Синең эзләр белән,
Синең күзләр белән,
Синең сүзләр белән тулы бәхетемне.
Бер канатсыз кичтем мин бу төнне.
Алтын аен яшергәне өчен,
Төн дә миннән гафу үтенде.
Ай кирәкми бүген, алсу гөл дә,
Бер җылы сүз кирәк, үтемле,
Сөю төсе җуелмасын өчен...

* * *

Буранлы юл...
Сызгыралар
Телефон чыбыклары.
Китәсем бар
Бу тынгысыз
Чикләрдән чыгып ары.

Ишерделәр
Тавышыңны,
Буран гүя белмәде.
Өзелделәр
Үзәкләрем,
Чыбыклар өзелмәде...

Юк, тынмаслар
Баганалар,
Мин тынгысыз булганда.
Тавышыңны
Эзләп барам,
Адашкандыр буранда...

* * *

Онытa алмам! Бу — җанга
Иң ачы җәза, басым.
Килә күзләр ялкынында
Газабымны ягасым.

Яфрак итеп яндырасым,
Көлен ташлап җилләргә.
Никләр әзер һәрбер очкын
Синең хакта сөйләргә?

Синең дә бит йөзләрендә
Югалтулар сагышы...
Бәлки, безнең өлешләргә
Тигән көмештер шушы.

Һәр очкында газаплану,
Җирдән ашу күкләргә.
Икебез дә әзерме без
Шул очкынны чүпләргә?

Могҗизалар күрмәк булып
Офыкларның артыннан,
Безнең кадерле мизгелләр
Очкын сыман атылган.

Яна гомер, яна көннәр,
Ә учаклар бер тына,
Утлы көлләр сүнәр беркөн,
Сүнмәс сөю-ут кына.

* * *

Җаннарында вокзал ачтың мәллә?
Узгынчылар, һаман юлчылар...
Төенчекләр төсе уйнап тора,
Юлчылардан һәрчак юл чуар.

Мин дә шундый бер узгынчы бугай,
Йөкләремне тартып киләм дә
Хәл алырга кагылмакчы булам,
Туктап калам ишек келәндә.

Керми китәм. Вокзаллар ят миңа,
Бу дөньяның барча ятлары
Арасында янып үтә гомер,
...Дип уфтанып куйган чак бары...

* * *

Өзелеп көттем лә бүген,
Ак ай төнне көткән кук.
Кояш, таң тугач сөенеп,
Энже чыкны үпкән кук.

Соңгысы булмас бу көтү,
Күзләрем янә талыр.
Сөю — мәңгелек! Ә безне
Ай күрер, кояш алыр.
Синнән дә, миннән дә җиргә
Якты мәхәббәт калыр...

## Моң

Мине танымаска әзер,
Әзерсең күрмәскә дә.
Карашыма чагылмаска,
Күзләргә кермәскә дә.

Әллә ни булган? Әллә ни?
Яз үткән дә кыш булган.
Мин сулаган бу һавага
Синең сөю кушылган.

Кышлардай салкын чагында
Таныма да, күрмә дә.
Ни охшашлык көнем белән
Күземдәге сөрмәдә?

Кылларыңны чиртә бер моң
Җаныңдагы төрбәдә...

## Елмаю

Үпкәләшеп алабыз без кайчак,
Нәниебез йоклаганда кичен.
Минем кебек, аяк очларыңа
Басып йөри белмәгәнең өчен.

Уйнатасың, имеш, очыртасың,
Түшәмнәргә тия яза башы.
Мин үпкәлим сиңа, улым көлә,
И гөлкәем минем, йөзек кашым!

Үпкәләшеп алабыз без кайчак,
Бер дә юкка сүзгә килгәләшеп.
Нәниебез елмаюы була,
Көлешәбез аннан бергәләшеп.

## Умырзая

Суык тидерми сакла, дип,
Сиңа гына әйтә алам.
Мин бит язгы умырзая.
Карлы тау — эссе далам.

Кояшка үреләм таңнан,
Җир тарта тамырымны.
Җил көтә ак һәм шәмәхә
Алкалар тагарымны.

Карлы тау — эссе далам ул,
Нур — йортым, юктыр тиңе.
...Суык карашыңнан сакла,
Үзеңнән сакла мине.

* * *

Өйрәт мине, өйрәт, дөнья,
Югалтмаска тапканны.
Утка очкан күбәләктәй —
Нишләтәсе бу жанны?

Мең төрләрдә балкый тормыш,
И чыда, жаным, чыда:
Мизгеллек бәхет мәңгелек
Югалту булып чыга...

И чыда, һәр дулкыныма,
Күңел ярыма бәргән.
Мин генәме елтыр-елтыр
Тәтиләргә ияргән?

Мин генәме ил-көнемә
Сабый сыман ышанган,
Югалтудан күңел тулып,
Елый-елый бушанган?

Офыклардан бәхет көткән
Чаптар атлар ялында...
Ә барсы да жанда булган,
Ә барсы да янымда.

Карап торам, монсу бушлык
Бер гомерне якканны.
Ничек өйрәнәсе, дөнья,
Югалтмаска тапканны?

## Якты сагыш

Мең мәртәбә рәхәт мина бүген,
Тапталмаган хисем өчен рәхәт,
Тапланмаган җаным өчен рәхәт,
Синсез булган өчен кичем рәхәт.

Мең мәртәбә җиңелерәк бүген,
Бик еракка синнән киткән өчен.
Һәм хыялның соңгы ноктасына
Ялгыз коштай очып җиткән өчен.

Мәхәббәткә чикләр барын белмим,
Ышансам да йөрәк туктасына.
Күземнең бер әче нуры тамды,
Якты сагышымның шушы мәлдә
Әверелеп соңгы ноктасына.

* * *

Онытalмыйм, дигәндә,
Онытып була инде.
Уттан алып күңелне
Җылытып була инде.

Син әйтәсе сүзләрне
Мин әйтеп була инде.
Ялган белән ялганны
Күбәйтеп була инде.

Ялганга ышанганны
Тиле дип була инде.
Шулай узган гомерне
Көйле дип була инде.

## Быелгы кыш

Быелгы кыш миңа гашыйк булган бугай,
Калдырмады ялгызымны бер көнгә дә:
Учлап-учлап энже сипте тәрәзәмә,
Күз атмасын, дип, тыштагы беркемгә дә.

Быелгы кыш миңа гашыйк булган бугай,
Исемсез гөл бүләк итте тәрәз аша.
Ә гөлләре тәрәзәмә туңган көе
Кышлар буе яшәргә дип ризалаша.

Быелгы кыш чынлап гашыйк
булган бугай,
Ләкин аңа бик салкынмын,
бик салкынмын...
Чөнки мин дә, ярым өчен дөрли-дөрли,
Кышлар буе янып торган ут-ялкынмын.

* * *

Табыныма ап-ак эскәтерләр җәйдем,
Якты өстәп торсын әле ак бүлмәмә.
Әйткәннәр бар: үзең өчен яшә, диеп,
Дуслар белән алма да, дип, һәм бүлмә дә.

Табыныма ап-ак эскәтерләр җәйдем,
Шатлыгымны дуслар белән бүләсем бар.
Башларыма ишелеп хәсрәт төшкән чакта,
Уйлаганда: «И Ходаем, үләсем бар...»

Дуслар килеп, күңелемә аклык җәйде,
Кара кайгы кергән чакта бүлмәбезгә.
Каршы алып озатырдай дусларым бар,
Шатлыгы да, хәсрәте дә кунак безгә.

* * *

Без икебез бергә янсакмы,
Ниләр кылыр идек ул чакны?
Без икебез бергә кабынсак,
Булыр иде галәм учаклы.

Икебез дә бергә кабынсак,
Якты калыр иде дөньясы.
Ялгыз яну — безнең язмыштыр,
Ургыйсы да янә тынасы...

Уйладым да сине, күгемдә
Өметләрем нурдан чигелде.
Без икебез ике балкыш шул —
Йолдыз белән яшен шикелле.

* * *

Син мине иләсләндермә
Утлы карашың белән.
Мин яна-яна яшим бит
Һәм яна-яна үләм.

Үлеп терелэм һәр сүздән,
Син әйткән өчен генә.
Шаһит юк яныма түгел,
Җаныма күчүенә.

Шаһит түгел алтын ай да,
Түгел көн яктысы да.
Җаныма яшердем сине,
Җанымның яртысына.

Уйнак уеңны яшердем,
Уйнаклаган кашыңны.

Күзләреңне, сүзләреңне,
Яшердем карашыңны.

Коеларга салдым гүя,
Коеның төпкеленә.
Беркөн җан да янар шунда,
Калыр кебек көл генә.

Бу барыбер синле чагым,
Диеп, йөрәк теленә.
Синең исемеңне язар
Язмыш калган көленә...

* * *

Ай нурлардан басма салган иде
Син яшәгән елга ярына.
Дулкынлы төн гүя әле һаман
Аргы якка дәшеп ялына.

Син йөгереп килә идең шуннан,
Ә мин горур идем ул чакта.
Көлә-көлә көнләштерә идем,
Салкын дулкыннарны кочаклап.

Ай нурлардан басма салган иде,
Челтәр-челтәр иде басмасы.
Аны алсу таңнар урладымы,
Алып китте мәллә башкасы?

Юк, яшьлеккә кире кайтып булмый,
Сагынуларга кала чыдасы.
Сиңа каршы, их, бер татлы төштә
Шул басмадан йөгереп чыгасы.

* * *

Үтмәс кышның суыклары
Тулган көнемә шыплап.
Ак бураннар саклый мине,
Кайгылардан ышыклап.

Битләрем алсу итәдер,
Һәм ярсудыр йөрәгем.
Ак бураннар арасыннан
Бәхет эзләп йөр әле!

Эзләдем. Таптым. Югалтмам.
Син миңа ап-ак тылсым.
Буранлы булып торсын көн,
Ап-ак ак булып торсын!

## Тамчы

Чәчләремнән сулар сыкмадым мин,
Һәм диңгезгә серем түкмәдем.
Кызыкты да кояш көлә-көлә,
Чәчләремнән тамчы чүпләде.

Җилләр килеп дулкын тарап алды,
Ярга гүя дулкын чәчелә.
Мин бит аны бәйләп кайтмак идем,
Толымнарга үреп чәчемә.

Бер дулкыннан якты тамчы калды,
Җәйләр эзләп, җанга сарыла.
Вакыт-вакыт диңгез булып кага
Минем шаулы күңел ярыма...

* * *

Ялгыш кына очраштык та,
Үптем дә ялгыш кына.
Җанга-җан беләп кагылып
Үттем дә ялгыш кына,

Шырпыдай кабындым кинәт,
Учаклы минем урам.
Юлларыңа якты сибеп,
Йолдыздай янып торам.

Кояштай балкып торганда,
Болыты каплап китә.
Сагышлы итә күгемне
Һәм мине уйлы итә.

Шырпы бирми сыный тормыш
Төннәрдә абынганын.
Аңлавым бу — язмышларның
Ялгыштан кабынганын.

* * *

Син миндә яшисең, гүя
Дөньядан киселгәнсең.
Якты сагыш тавы булып,
Җаныма ишелгәнсең.

Ул чакта мин дә тетрәндем,
Җан тулы вулкан иде.
Өметләрең йөрәгемдә
Кыя тау булган иде.

Мин сине саклап калдым күк,
Син миндә яшисең бит.
Бәлки, үзең белмисеңдер,
Белсәң дә дәшмисең бит.

Дөнья — табышмак. Кызык ул,
Җавабы чишелмәсә,
Сине яшереп яшәткән
Үз кыям ишелмәсә.

* * *

Ак чаналар язга алып китте,
Энҗе карлар калды уйнаклап.
Ап-ак кичләр калды көртә чумып,
Безнең арттан барды ай атлап.

Мин, йомарлап, айның кочагына
Атмакчы идем утлы йөрәкне.
Тотып калдың:
— Күр, ак карлар ява,
Артка карама әле, кирәкми...

Ак чаналар язда янган... Ә без
Гөрләвекләр буйлап киткәнбез.
Адашканбыз... Ике яклап айны
Эзли-эзли, еллар үткәнбез.

Айны күрсәм, һаман кочагына
Атмак булам туңган йөрәкне.
Нидер тота:
— Яшел җәйләр алда,
Артка бакма, җаным, кирәкми!..

* * *

Күктә яралган тамчылар
Төшәчәк беркөн җиргә.
Гөлләр, үләннәр үсәчәк,
Дәва булып мең чиргә.

Җирдә туганмын, яшәвем
Шул туфракка бәйләнгән.
Мине дә күкләр алыр бер
Тормыш дигән бәйрәмнән.

Кояшның бер нуры булып
Биепләр китәрмен дә,
Тамчылар көлеп уяныр
Чәчәкләр үтәгендә...

* * *

Үкчәләр үз көен көйләр,
Ишетмәс яшь туташлар.
Төнге асфальт серле хәтта,
Һай, салкын төнге ташлар.

Чыныгыр йөрәк, хисләр дә
Утларда янмый башлар.
Җәй. Көн үзәге. Юлларда,
Һай, кайнар соң бу ташлар...

* * *

Энже бөртек учларына төште,
Уйный-уйный төште һавадан.
— Юк, табигать мондый гүзәллекне
Иҗат итә алмас янадан! —

Диден дә син, мина суздың аны,
Бүләк булсын, диеп, кышлардан.
(Буш хыяллар, буш вәгъдәләр күпме,
Бу истәлек, беләм, бушлардан...)

Ә ул чакта җил көнләште миннән,
Дулап-дулап шашып йөреде.
Мин, сөенеп, учларымны суздым:
Энже бөртеккәем эреде...

## Бөре

Агасы сулар да аккандыр,
Исәсе җилләр дә искәндер.
Яз килгәч, яфрактай талпынган
Чагында әле мин исәндер.

Җил булып исәмдер әле мин,
Көннәрдән җылы наз сизелә.
Хисләрне яз килеп янарта,
Көз җитсә, яфрак та өзелә.

Син дә тын калырсың кабаттан,
Йөзеңнән тынычлык бөркелер.
Әмма мин — мин бөре — исәндер,
Әмма яз ел саен бер килер...

# Таяныр ноктам

Кайгыңны юасым килә,
Суларга салмый гына.
Яшең киптерәсем килә,
Сөртепләр алмый гына.

Утка салсаң, ут көл булыр,
Су кибәр, салсаң суга.
Мин яраңа сүзләр урыйм,
Әйләнсеннәр даруга.

Дәвалыйсым килә сине,
Хәсрәтең — тирән яра.
Икәү бергә әрни-әрни,
Икегә бүлдек, кара!

Көлләр очар, юар вакыт,
Җиңсәң, хәсрәт — көл бит ул.
Башны ташка ормак булган
Без генә түгел бит ул.

Икегә бүлдек яраңны,
Үзәккә үтә... Үзгә.
Сүзгә урыйм. Үземнең дә
Таяныр ноктам — сүздә.

* * *

Яшьлегемә гашыйк булгансың бит,
Ялгышкансың гына уенда.
— Йөзек кемдә? — диеп сорап булмас,
Учларыңа салып уенда.

Кем учында калды ул йөзекләр?
Кире кайтмас ул кич дәшеп тә.
Нинди бәхет! Сокланыплар торсам
Беркөн мин дә шулай яшьлеккә...

* * *

Дөньядагы изге туктальшмы,
Алтынсу төс сайлап буялган:
Мин һаман да синең аша очам,
Синең аша үтәм хыялга.

Юлым унмый, диеп каһәрләмим,
Ни күрсәм дә үзем күрәсе!
Күңелләрем керле булса, беләм,
Ярдәм итмәс Коръән сүрәсе.

Кызгылт-сары төсләр аша күрәм,
Күзләр аша күрәм кояшны.
Узган саен туктальшлар кала,
Алтыннарга манып буяшлы!

Кемнәр туктар анда? Мин туктамам,
Мин очармын алга һәм алга!
Никтер һаман синең аша узам,
Синең аша үтәм хыялга...

* * *

Синсез кыен миңа бүген,
Нигәдер кыенырак.
Адымлап якын аралар,
Йөрәкләр шундый ерак.

Сүзләрдә кышлар салкыны
Сибелә читкә генә.
Нишләрмен, туңса бу йөрәк
Иң соңгы чиктә генә,

Дип уйлыйм да, эри жаннар,
Яшерәбез күзләрне.
Сиздермибез, күңелләрнең
Бар дөньясы үзгәрде.

Яктырды, сүзләрдән гүя
Коелды салкын ташлар.
Тик карашлар очрашты,
Ах, бәхетле карашлар...

## Балыкчы янында

Бөртек карлар монда зәңгәр күзле,
Зәңгәр ярга йөгерә кылганнар.
Дулкыннар да зәңгәр керфекләрен
Какмаска дип тынып калганнар.

Зәңгәр һава булып, балыкчының
Карашлары жанга тулыр күк.
Хыялдагы тере алтын балык,
Булса, бары шунда булыр күк.

* * *

Мин сине яраттым,
Яраттым ялгышып,
Ялгыштан сакларсың син генә.
Ә җанга, энҗе кар бөртеге шикелле,
Кыш тулы карашың сибелә.

Мин сине яраттым.
Ялгышып. Карышып
Буламы кояшның нурына?
Һәр бөртек — бер кояш.
Бу — синнән бүләктер,
Җаныма коелып ургыла.

Мин сине яраттым.
Яраттым ялгышып.
Син, бәлки, белмәссең бу хакта.
Мин — күктә, ә җиргә энҗе кар коела,
Шул җиргә төшүдә мең хата...

* * *

Син ят түгел ак ташларга
Яшьлегең каласында.
Берүзеңә яз калдырам
Ландышлар арасында.

Ап-ак энҗе чәчкәләрнең
Исер әле исенә.
Бу мизгелләр, бер гомердәй,
Төшәр әле исеңә.

Китеп барам. Кичерерсең
Онытып барысын да.
Берүзеңә яз калдырам
Ландышлар арасында...

# Тәрәзәмә пыялалар куясың син

Тәрәзәмә пыялалар куясың син,
Алмаз белән кисәсең син өлге-өлге.
Читтән генә күзләреңә карап торам,
Кулларымда сиңа диеп чиккән сөлге.

Менә янә минем ватык тәрәзәмнән,
Бураннарга юл күрсәтеп, җилләр керде.
Түремә үк кунаклады яфраклы җил,
Күр син аны, шундый салкын, шундый тере.
Тәрәзәмнең элдем ватык өлгесенә, —
Син күрмәгән сөлге бит ул, син белмәгән.
Җылы, назлы карашыңны чыгармыйча,
Саклап, бәйләп тотып торган бу бүлмәдән.
Бүлмәмдә җил хуҗа булып уйнап йөри,
Аның янда үзеңне чит тоясың син.
Ә мин менә көлә-көлә карап торам,
Тәрәзәмә пыялалар куясың син...

* * *

Эзләреңә басып үттем,
Ап-ак иде сукмагың.
Һәр якты кар бөртеген мин
Җанга салып чутладым.

Бәхетле кар бөртекләре!
Көнләштем һәрберсеннән.
Әмма аларга сиздереп,
Авыр итеп күрсенәм.

Ә иртәгә үтәчәксең
Басып минем эзләргә.
Яктырак күренер кебек
Сукмак синең күзләргә...

Ах, безгә соң, белмим, ничек
Бу аклыкка түзәргә?!

* * *

Оҗмахы да, тәмугы да —
Барысы да алда булыр.
Адәмне дә саташтырган
Мин сузган алма булыр.

Мин дә Һава синең өчен,
Мин дә мең кат гөнаһлы.
Алма алсулыгы җанда,
Хыяллар шул гел аклы.

Минем хакка оҗмахларны
Алыштырсаң тәмугка,

Сызланмассың яшәвендә
Ямь юкка да тәм юкка.

Алмаларга алданганнар
Көн янадыр, төн яна.
Янмый яшәү яшәүмени
Бу гөнаһлы дөньяда?

Алмагачлар шау чәчәктә,
Яз, чәчәге өр-яңа.
Чәчәк чактан, әй, кызыгып
Карап торабыз аңа.

Адәм белән Һава шул без
Бу гөнаһлы дөньяда.

* * *

Көтмәдем. Килмәдең.
Бәгырьне телмәдең.
Сагынмам, сагынмам,
Син үзең теләдең.

Сарылмам яңгырдай,
Күз атмам юлыңа.
Син үзең теләдең,
Әйләнмәм колыңа.

Бу горур җанымны
Кимсетмәм барыбер.
Син үзең теләдең.
...Ә сөю бары бер.

* * *

Менләгән яшен ташларын
Учыңа җыя-җыя,
Ул чакта минем йөрәктән
Тапмакчы идең оя.

Мизгелдән кабынган ялкын
Үрмәләде күкләргә.
Яшен булды. Ә яктысы
Күренде шул күпләргә.

Сине сукмый тәгәрәде
Яктысы ул яшеннең...
Ә мин гүя йөрәгемә
Утлы ташлар яшердем...

## Тәрәзәмдә ак кар уйный

Күзләрем нуры түгелә
Тузылган өстәлемә.
Урамда мәрҗән кар ява,
Сибелеп, өстән генә.
Карлар уйный. Тар бүлмәмдә
Улым уйный ат куып.
— Атлы уйнап туйдым, әни,
Кабартыйк, әйдә, куык.
Күтәреп ала әтисе:
— Әниең яза, тимә.
Тәрәзәмдә ак кар уйный,
Һәр бөртек — мәрҗән төймә.
Карлар — төймә, балам — төймә,
Һич тә алыштыргысыз.
Киң дөньяма ак нур ява.
Сөенәм, мин — хатын-кыз.

# Салават күпере

Мең төсне сыйдырган дөньяда
Матурлык — үзе үк изгелек.
Салават күперем — син минем,
Кызыккан, югалткан мизгелем.

Тибрәләм җиде нур эчендә,
Син минем — салават күперем.
Болытлар шикелле, ирektә
Уйларым йөзәләр күпереп.

Гомерем — шул төсләр балкышы,
Җир-күкләр — чишәлмәс төенем.
Төсләре җуелмас яшьлектә
Салават күперем — син минем.

# Бер көн сездә ява

Күк күкрәгән саен түгелеп төшә,
Бер көн сездә ява, бер көн бездә.
Һәр шыбырдау — татлы хатирә ул,
Бер үк халәттәдер икебез дә.

Күк күкрәве сыман язда яшьлек,
Тамчылардай көннәр коелып калган.
Безне күтәрердәй ул вәгъдәләр,
Күр, салават күпередәй ялган
Булган икән.
Тагын коя гына,
Шул тамчылар кебек, икебез дә
Җиргә төштек күптән.
Әле дә яңгыр
Бер көн сездә ява, бер көн бездә...

* * *

Минем өчен дөнья беткән иде,
Җир ычкынган иде кучәреннән.
Диңгезләрдә сулар кипкән иде,
Тамчысы юк иде эчәремә.

Җыйналганнар иде җәйләр, кышлар,
Бу халәтем үтмәс кебек иде.
Мин таянган вакыт яктылыкка
Алып чыгып җитмәс кебек иде.

Оныттырмас кебек иде сине
Сагышлы ай һәм йолдызлар иле.
Тар күкләргә сыймый идем ул чак,
Кара болыт миңа күлмәк иде.

Менә бүген, ак тамчыдай тамып,
Хәтеремә төштең көтмәгәндә.
Еллар үткән, хәтта гасыр үткән,
Дөньям исән! Дөнья бетмәгән лә.

Хәтер исән! Яшьлек үтмәгән лә...

* * *

Кыенлык китермәм мин сиңа,
Алмадай кызармас битләрең.
Син ачып керәлми торганда
Дөньяның иң олы бикләрен,

Ярдәмгә йөрәгем сузармын,
Бик кыен булса да үземә.
Алмадай кызарып битләрем
Җәйләрдәй һәр җылы сүзеңә.

Җиңеллек китермәм мин сиңа,
Җилләрдәй өметең таратып.
Ә беркөн хәтерең түренә
Алмадай төшәрмен тып та тып...

* * *

Бүген никтер синең хәбәрең юк,
Кош теледәй сүзең килмәде.
Бүген мине читләп-читләп үтте
Сезнең яктан искән җилләре.

Бүген хәбәр көтмәдем дә юкса,
Күзем түгел, көзем тала күк.
Үткәннәргә хәтта кайта алмыйм,
Бүген көнем ятим бала күк.

* * *

Ак бураннар шашып туй иткәндә
Декабрьнең аклык күчендә,
Һәр бөртекнең күңел күкләремә
Кыңгыраулар таккан кичендә,
— Туйларына чакыр мине... — диден, —
Мең бормалы тормыш юллары...
Декабрьнең ап-ак бураннары
Йөрәгемә ятып елады.
Көтмәгәндә җиргә иңеп калды
Бураннарның зифа буйлары.
Күзем күргән һәрбер ак бөртекнең
Синең хакта иде уйлары.
Ә юллары мең бормалы икән,
Син ничекләр алдан белгәнсең?
Яшәгәнче әллә картайгансың,
Туганчы ук әллә үлгәнсең?
Адашкансың ап-ак бураннарда,
Югалгансың шунда хәбәрсез.
Мин кышлардан хатлар көтмим инде,
Хатлар килмәс бер-бер хәлләрсез...
Декабрьнең ап-ак бураннары,
Гомер башы — кышның башлары.
Хужа булып җанга, исемеңне
Дулый-дулый алып ташлады.
...Ак туфлидән ак карларга бастым,
Ап-ак гөлләр минем куенда!
Декабрьнең елак бураннары
Искә төшеп куйды туемда.

* * *

Мин сине эзләгән идем шул,
Табарга теләгән идем шул.
Югалту яшергән җаныма
Өметләп түләгән идем шул.

Мин сине эзләгән идем шул,
Эзләми түзмәгән идем шул.
Син, диеп ялгышып, күкләрдән
Бер йолдыз күзләгән идем шул.

Мин сине эзләгән идем шул.
— Юкка!
Кул изәгән идем шул.
Син килер сукмакны барыбер
Гөл белән бизәгән идем шул.

Мин сине көтмәгән идем шул,
Син килдең, түзмәгән идең шул.
Җаныма уралды сүзләрең:
— Мин сине эзләгән идем шул...

* * *

Их, таңнарны капка төптә
Аттырасы иде бер.
Ай кергән тәрәзә булып
Ярътырасы иде бер.

Их, яшисе синнән башка,
Беркемне уйламыйча.
Ак тузганактай җилпенеп,
Җәйләрне коча-коча.

Их, бер яратасы иде,
Уйсыз башны югалтып.
Белмичә җилләр исәсен,
Җәй үтмәс, дип юатып.

Һәм барсын да югалтасы...
Елыйсы көлә-көлә.
(Күрче, үземнән үземне
Кызгандырасы килә.
Һәм нигә?) Яктыра җаным,
Хәтер канаты тисә.
Башларын югалткандырмы,
Иләсләнеп җил исә...

* * *

Күзлисе идем мин энәмә ай нурын,
Чигәргә яулыкның матурдан-матурын.

Бик телим ак төннең уемны белгәнен:
Ай сыман, тәрәзгә сөйгәнем килгәнен.

...Нурдан ут кабызып,
мин яндым микәнни?
Ул — чигеш җебе, дип
алдандым микәнни?

Ай аны биргәндер башка бер чибәргә,
Гади җеп күзләдем төн ямен чигәргә.

Ах, җебем чуала! Җил уйдан аралый:
Нур — сөю җепләре, чуалту ярамый!

* * *

Мин яратам быел яуган карны,
Былтыргыдан аграк булган өчен.
Мин яратам быел килгән кышны,
Былтыргыдан ерак булган өчен.

Бураннарга кушылып китәр бу кыш,
Килгәннәргә беркөн киту язган.
Чын аклыкны танып калдым, шөкер,
Кыш аклыгын эзләрмен мин яздан...

# Татар бае

Татар бае хәтәр кәнәфидә
Чәйләр эчә, ала җилләп тә.
Ә мин башым иеп аңа килдем,
Ярдәм кирәк, диеп, милләткә.

Милләт сүзе телләреннән төшми,
Тыңлар, дидем, аңлар бер тыннан.
Башым иеп чыгып киләм менә
Һуш китәрлек затлы йортыннан.

Яңа гына берәү килгән икән:
— Милләт, — диеп, — гәҗит укысын. —
Булыш, әйдә, синдә күп бит алар,
Яздыр әле татар ул-кызын.

Һәм үкенеп чыгып киткән ул да,
Ник кергәнгә затлы йортларга.
Чүп-сүзләре чынаякка төшкән,
Һинд чәйләрен ипләп йотканда.

Күпләр йөри байлар тирәсендә,
Пенсионер, мескен, теләнче,
Йә намуслы, йә акылга таман,
Милләтем, дип яна үлгәнче.

Хәер, мин дә шулар арасында,
Ярдәм кирәк, дидем, милләткә.
Заман... Тарих... Никтер күзем төште
Чәйнегенә элгән иләккә...

## Сүзләр

Ялган булып тумый сүзләр,
Кеше теле ялган итә.
Энже итә, мәрҗән итә,
Кирәк чакта калкан итә.

Ямьсез булып тумый сүзләр,
Кеше теле ямьсез итә.
Төссез итә, тозсыз итә,
Ачы итә, тәмсез итә.

Татлы булып тумый сүзләр,
Телгә керсә, нур иңәдер.
...Үз сүзеңә ия булу —
Байлыктыр ул, хәзинәдер.

* * *

Җимешле көз, сау килдеңме? Алмаң
Алларыма төшкәч, сизгәнмен.
Күреп тордым юкса сеңелемнең
Балан муенсалар тезгәнен.

Юкса әнкәм кичә дәште бугай:
«Хушлашулар авыр, тын кыса...»
Кыр казларын озатканын сөйләп,
Тынып калды — үзе бер кыйсса.

Юкса әби, көзне түргә әйдәп,
Чебиләрен инде санаган.
Төшкән яфракларның, аккан суның
Кайтмауларын белә янадан.

Җимешле көз, сау килдеңме, җаным!
Ничек басыйм хисләр ярсуын.
Алма җыяр чагым. Алларымнан
Сайлап-сайлап җыйыйм алсуын...

# Хыял канаты

Шатлыкларың көнгә сыймый,
Бар да үз, юктыр яты.
Әллә инде иңнәрендә
Минем хыял канаты?

Нәкъ минем күк йөзәсең бит
Җиденче кат күкләрдә.
Әллә шуңа чишелешсез
Табышмак без күпләргә.

Кесәң буш та! Яшәр чакта
Борын белән җир сөреп.
Күктә очып барган кебек,
Кара әле җирдә йөреп!

Юкса дөнья бер генәме
Борыннарны канатты...
Күрәм, синең иңнәрдә дә
Минем хыял канаты.

# Эчтәлек

Сигезенче могҗиза . . . . . . . . . . . . . . . . 5
«Ай еракта...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Тузганак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Үз көнем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
«Октябрьдә тумаганга...» . . . . . . . . . . . . . 9
Ядрәләр ярыла . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
«Биләр җире тоташ каберлек, ди...» . . . . . . . . 11
Себердә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Сөлге тотып торучы юк юлларымда...» . . . . . . 13
Изге Биләрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Нинди ил бу? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Иман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Кызганам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Йөрәк сызлый . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Сорадылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Якты юл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Казаннан кайткач . . . . . . . . . . . . . . . . 19
«Мин барыбер читкә китә алмам...» . . . . . . . . 20
«Килен булып төшкән мәле кышның...» . . . . . . . 21
Хәерле рух . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Юл кичүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Бизмәнче карт . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Һәйкәлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
«Керфеккә эленгән төн нуры...» . . . . . . . . . 25
Таң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Чегәннәргә кызыгу . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Бөеклек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27

Кибеттә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Әрнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
«Чишмәләргә челтерәүләр кирәк...» . . . . . . . . 29
Ватаным . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Йөк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Туган телем . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Шулайдыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Фирүзә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Туган якта . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
«Алмагачка бик авырдыр...» . . . . . . . . . . 35
«Карлар ята нарат түбәсендә...» . . . . . . . . 36
Чит тәрәзләр . . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Дөнья булгач, төрле чаклар була...» . . . . . . 37
Теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Капка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
«Мин ашыгып еллар буйлап узам...» . . . . . . . 39
Без яшь чакта . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Төзелештә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
«Мин язам үзем булып та...» . . . . . . . . . . 41
«Ничә яшь, дип сорамагыз миннән...» . . . . . . 42
Күмер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Яңа моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
«Түтәл тулы суган тузгып ята...» . . . . . . . . 43
Хатын-кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Әнкәй кайгысы . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Кайтаваз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Ташлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Исән чакта . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Көнбагыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Усак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Яшь ана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Май шәфәгы . . . . . . . . . . . . . . . . . 50

Сәхнә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
«Яну серен утка өйрәтмиләр...» . . . . . . . . 51
Хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Җиләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Сөенеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Диңгез ярында . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Күбәләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Яктылык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Соңгару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Көзге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Чык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Аптырагач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Дәвам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Җил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Ике көч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Гыйбрәт корбаны . . . . . . . . . . . . . . . 59
«Кемдер йолдызлар кабыза...» . . . . . . . . . 60
Сәер заман . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Гөл өзмәгез . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Наз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Зонтигым — сәхнә . . . . . . . . . . . . . . . 62
Кактус гөле . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
«Сәламемне алмый үтте түрә...» . . . . . . . . 63
Көзге яфрак . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Күчтәнәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Май салкыны . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Туган йортымда . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Көзге уй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
«Зәңгәр күкләр йокыларга талган иде...» . . . . . . . 66
Туп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
«Кич укылган әкиятләр аз булган...» . . . . . . . . 67
Уен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68

Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Язгы кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Әйтерсең лә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Ятимнәр кышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Хыял бизим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Уйлы җил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Еллар — еланнар . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Нигез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Их, нарат лар! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Күз һәм малай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
«Син дөньяны төзәтергә телисеңдер...» . . . . . . 74
«Терәүләре ауганны да...» . . . . . . . . . . . . . 75
Юл башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
«Урамыма күзләр кертмим, диеп...» . . . . . . . . 77
«Туган яктан ерак киткән саен...» . . . . . . . . 77
Яшим! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
«Йолдыз мин, дип хис итәдер...» . . . . . . . . . 79
«Кешеләргә рәнҗемәскә иде...» . . . . . . . . . . 79
Кыйбла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
«Җир читенә китсәм — ерак булыр...» . . . . . . 81
«Минем бәхетле халәтем...» . . . . . . . . . . . . 81
Бетергеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
«Без юк җирдә тормыш рәхәт инде...» . . . . . . . 82
Гүзәл төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Үтелгән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
«Тешләр тешкә тими иде...» . . . . . . . . . . . 84
Күтүче җәе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Бәхетне табып буламы? . . . . . . . . . . . . . . 85
Әбиләр чуагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Яшәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
«Ышанасың кайчагында...» . . . . . . . . . . . . 88
Туганым, дигәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Вәгъдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

Яңа ел чыршысы . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Карт яһүд . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Юлчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Бишле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
«Кыз бала учлый да суларга ком ташлый...» . . . . . 93
Җепләр эрлим . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Күпләрне үзгәртә акча . . . . . . . . . . . . . 94
Зиратта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Автобуста . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Хыял . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Тын иртәдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
«Мин шигырьдән киткән идем инде...» . . . . . . . 98
Яңа шәһәрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
«Өзелде дә төште яшел яфрак...» . . . . . . . . . 11
«Кемнәр бүген бриллианттыр...» . . . . . . . . . 101
Ялгызлыгым . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Яңа ел көткәндә . . . . . . . . . . . . . . . 103
Нокта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
«Адымнары җилләр кебек җиңел...» . . . . . . . . 104
Сөенче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Көтелмәгән бию бии...» . . . . . . . . . . . . 106
Юлга чыгам . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Кабатланмый . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Гармун тотсам . . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Юлга төшкән яфрак нинди якты!» . . . . . . . . 109
Язгы кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
«Мин белгән берничә йолдыз бар...» . . . . . . . 110
Могҗиза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Каз өмәсендә . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
«Чикләвек ватарга сау тешләр җитәдер...» . . . . 113
Алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Көзге шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Туган җир . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115

«Иренеңә җыерчыклар төшкән...» . . . . . . . . 116
Йөрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
«Юк, үземне биек итеп күрмим...» . . . . . . . 117
Күңел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Кунак булып кына . . . . . . . . . . . . . . . 118
«Халкым кебек, моңнары да...» . . . . . . . . 119
Уйламыйча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
«Хыялымдай...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
«Мин юллар табалмый йөргән...» . . . . . . . 121
«Соң өлгердем...» . . . . . . . . . . . . . . . 121
Балачак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Гөлле өйгә төс керә . . . . . . . . . . . . . . 123
Талантлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
«Тагын кич...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
«Бер сукмактан йөри...» . . . . . . . . . . . . 125
Үземчә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
«Ташлар булып булмас инде...» . . . . . . . . 126
«Керфек кагарлык хәлем юк...» . . . . . . . . 126
«Шатлыгымны сиңа бирәм, дөнья...» . . . . . . 127
Шигырем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Елыйм, көләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Ярый әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
«Сүз хакына энә күзләреннән...» . . . . . . . 129
Туктальш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
«Бүген минем тәрәзләрем якты...» . . . . . . 131
«Мин диңгездән бик еракта яшим...» . . . . . 131
Яз буласым килә . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Мәхәббәт тудырдым . . . . . . . . . . . . . . 132
Исемдә, дисең . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Сиңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
«Бәхетемне кыерсыттың бүген...» . . . . . . . 134
«Буранлы юл...» . . . . . . . . . . . . . . . . 135
«Оныта алмам!..» . . . . . . . . . . . . . . . . 135

«Җаннарында вокзал ачтың мәллә?..» . . . . . . . . 136
«Өзелеп көттем лә бүген...» . . . . . . . . . . . . . 137
Моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Елмаю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Умырзая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
«Өйрәт мине, өйрәт, дөнья...» . . . . . . . . . . . 139
Якты сагыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
«Онытилмыйм, дигәндә...» . . . . . . . . . . . . . . 140
Быелгы кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
«Табыныма ап-ак эскәтерләр җәйдем...» . . . . . . 141
«Без икебез бергә янсакмы...» . . . . . . . . . . . 142
«Син мине иләсләндермә...» . . . . . . . . . . . . . 142
«Ай нурлардан басма салган иде...» . . . . . . . . 143
«Үтмәс кышның суыклары...» . . . . . . . . . . . . 144
Тамчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
«Ялгыш кына очраштык та...» . . . . . . . . . . . . 145
«Син миндә яшисең...» . . . . . . . . . . . . . . . 145
«Ак чаналар язга алып китте...» . . . . . . . . . . 146
«Күктә яралган тамчылар...» . . . . . . . . . . . . 147
«Үкчәләр үз көен көйләр...» . . . . . . . . . . . . 147
«Энҗе бөртек учларыңа төште...» . . . . . . . . . 148
Бөре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Таяныр ноктам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
«Яшьлегемә гашыйк булгансың бит...» . . . . . . . 150
«Дөньядагы изге тукталышмы...» . . . . . . . . . . 150
«Синсез кыен миңа бүген...» . . . . . . . . . . . . 151
«Балыкчы янында...» . . . . . . . . . . . . . . . . 151
«Мин сине яраттым...» . . . . . . . . . . . . . . . . 152
«Син ят түгел ак ташларга...» . . . . . . . . . . . 152
«Тәрәзәмә пыялалар куясың син...» . . . . . . . . 153
«Эзләреңә басып үттем...» . . . . . . . . . . . . . 154
«Оҗмахы да, тәмугы да...» . . . . . . . . . . . . . 154
«Көтмәдем. Килмәдең...» . . . . . . . . . . . . . . 155

«Меңләгән яшен ташларын...» . . . . . . . . . . . . 156
«Тәрәзәмдә ак кар уйный...» . . . . . . . . . . . . 156
Салават күперем . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
«Бер көн сездә ява...» . . . . . . . . . . . . . . . 157
«Минем өчен дөнья беткән иде...» . . . . . . . . . 158
«Кыенлык китермәм мин сиңа...» . . . . . . . . . . 159
«Бүген никтер синең хәбәрең юк...» . . . . . . . . 159
«Ак бураннар шашып туй иткәндә...» . . . . . . . . 160
«Мин сине эзләгән идем шул...» . . . . . . . . . . 161
«Их, таңнарны капка төптә...» . . . . . . . . . . . 162
«Күзлисе идем мин энәмә ай нурын...» . . . . . . . 163
«Мин яратам быел яуган карны...» . . . . . . . . . 163
Татар бае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Сүзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
«Җимешле көз, сау килдеңме?..» . . . . . . . . . . 165
Хыял канаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

Литературно-художественное издание

Фируза Джамалетдинова

(Фатхутдинова Фируза Исламовна)

*Луна с косичками*

Стихи
(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *М.А.Жиһаншина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.12.2003.
Форматы 70×90 1/32. Офсет кәгазе.
«Korinna» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 6,44+форз.0,15. Шартлы буяу-оттиск 7,32.
Нәшер-хисап табагы 6,38+форз.0,24. Тиражы 2000 д. Заказ Я-882.
Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.